


азат хатын

3/85



КАДЕРЛЕ ДУСЛАР! СЕЗНЕ ХАЛЫКАРА ХАТЫН-КЫЗЛАР БӘЙРӘМЕ БЕЛӘН КОТЛЫЙБЫЗ!


LTH 250

БӘЙРӘМ ТАНТАНАСЫНДА

Д. С. ДӘҮЛӘТШИНА,
ТАССР Верховный Советы
Президиумы секретаре.

Табигать уянган таңда, язның беренче аенда ук без хатын-кызлар көнен бәйрәм итәбез. 1910 елда ук, социалист хатын-кызларның Копенгагенда үткәрелгән икенче халыкара конференциясе, Клара Цеткин тәкъдиме белән, 8 Март көнен бөтен дөньядагы хатын-кызларның экономик, социаль һәм политик тигезлек өчен көрәштә теләктәшлек көне итеп игълан итте. Халыкара хатын-кызлар көне — 8 Март быел җитмеш бишенче елын билгеләп үтелә.

Безнең илебездә, республикабызда бу бәйрәм тагы да күтәренке рухта үткәрелә. Февраль ахырында гына без җирле Советларга сайлаулар уздырдык. Алдынгыларның алдынгылары, шулардан бик күп хатын-кызларыбыз, РСФСР һәм Татарстан Верховный Советларына депутат итеп сайланды. Халык депутатларының авыл һәм район Советларында да эштә актив, тормышта үрнәк, булдыклы һәм инициативалы апа-сеңелләребез эшли башлады.

Хатын-кыз — ана, хатын-кыз — хезмәт кешесе, хатын-кыз — гаиләдә. Бу изге төшенчәләр безнең илебездә Бөек Октябрь революциясенең беренче көннәреннән үк дәүләтебезнең политикасы, социалистик җәмгыятебезнең әхлак нормасы булып әверелде. Безнең хатын-кызларыбыз яңа тормышны төзүдә үзләрен чын батырлар итеп күрсәттеләр: яшь Совет власте өчен көрәштә куркусыз революционерлар белән бергә атладылар, беренче бишьеллыкларның ялкынлы чакыруына кушылучылар алар булды, Бөек Ватан сугышы вакытында тылда һәм фронтта ныклык һәм какшамас рух күтәренкелеге күрсәттеләр. Сугыштан соңгы бишьеллыкларда да хатын-кызларыбыз фидакарь хезмәтләре белән җиңү артыннан җиңү яуладылар.

Хәзер безнең республикада 29 хатын-кыз тырыш хезмәте өчен иң зур бүләккә — Социалистик Хезмәт Герое дигән исемгә лаек булды. Дәүләт премиясе лауреатларыбыз күп, хөкүмәтебезнең орден-медальләрен зур горурлык белән йөртүчеләр бихисап. Илебезгә күп бала үстереп бирүче аналарыбыз да хөрмәтле. Республикада 2482 кешегә «Герой-ана» дигән мактаулы исем бирелде.

Күптән түгел хатын-кызлар советларының район конференцияләре булып үтте. Зур бәйрәм төсен алды бу җыелышлар. Хатын-кызлар, трибуналарга басып, ялкынлы речьләр сөйләделәр. Хатын-кызларның җәмгыятебездәге хәзерге роле, эш урынында, бала тәрбияләүдә, гаилә ныклыгын саклаудагы бурычлары турында сөйләделәр алар. Социалистик Хезмәт Геройлары, Герой-аналар, хезмәт һәм сугыш ветераннары — барысы да илебезнең чын хуҗалары булып, бүгенге халыкара хәл, илебез тормышы, көнебез торышы турында фикер алыштылар.

Февраль аенда республикабыз хатын-кызларының II съезды чакырылды. Беренче съезд 1927 елда Казанда үткәрелгән. Аңа 140 делегат катнаша, шуларның 72 се татар, 55 рус, калганнары чуваш, мари, мордва һәм башка милләттән булалар. Белем дәрәҗәләре дә хәзергечә югары, урта һәм махсус урта белемле дип түгел, белемле, аз белемле, белемсезләр дип билгеләнгән. Съездда катнашучылардан 89 кеше — белемле, 29 — аз белемле һәм 31 кеше белемсез була. Ләкин яңа тормышны төзү дәрте аларда көчле була. Эшче-крестьян хатын-кызларның Бөтенсоюз съездына 10 делегат сайлана. Бу вакыйгадан соң күп вакытлар үтте. Хатын-кызларыбызның аң һәм белем-дәрәҗәсе нык үсте.



Икенче съездга делегат итеп сайланган хатын-кызлар арасында ил күләмендә танылган кешеләр — Социалистик Хезмәт Геройлары, лауреатлар, Ленин ордены кавалерлары, беренче стахановчылар, Бөек Ватан сугышы ветераннары катнашты. Алар иҗтимагый-политик тормышта хатын-кызларны тагы да активлаштыру, яшь буынны тәрбияләүдә нәтиҗәле чаралар булдыру турында фикер алыштылар.

Моңа кадәр хатын-кызлар советлары авылларда, предприятиеләрдә эшләп килсә дә, алар белән җитәкчелек итүче махсус оешма юк иде. Республиканың хатын-кызлар комитеты партия өлкә комитеты ярдәмендә, ТАССР Верховный Советы Президиумы карамагында эшләячәк. Хатын-кызларның II съезды аның җитәкче органнарын сайлады. Комитет составына республикабызның иң актив, дәрәҗәле, алдынгы хатын-кызлары кертелде.

Язның иң матур бәйрәме көнендә данлы хатын-кызларыбызны — әбиләрне, әниләрне, апа-сеңелләрне Халыкара теләктәшлек көне — 8 нче Март белән тәбрик итәбез. Бәйрәм тантанасында сезгә гаилә бәхете, хезмәт уңышлары һәм ил-көнебезгә тынычлык телибез.

Барлык илләрнең пролетарийлары, берләшегез!



азат хатын

МАРТ 1985

Айлык иҗтимагый-политик һәм әдәби-нәфис журнал.
1926 елда чыга башлады

© «Азат хатын», 1985 ел.

БӨЕК АНА

Мария Александровнаның әнисе Анна, алты баласын калдырып, бик яшьли үлеп китә.

Әтиләре Александр Дмитриевич Бланк һәм апалары Екатерина Ивановна тәрбиясендә балалар мөстәкыйль булып, гади, шат күңелле булып үсәләр. Екатерина Ивановна балалардан чисталык, матур, табигый гадәтләр таләп итсә, аларның өйдәге бөтен төрле эшне эшли белүләрен теләсә, әтиләренең исә аларны физик яктан чыдам итеп, нәфессез, түзем, сабыр итеп, башкаларга карата гадел һәм игътибарлы итеп күрәсе килә.

Тирә-юньдәге кешеләрнең надәнлык турында сөйләүләрен күп ишетә Мария. Ул үзе үскәч әтисе кебек булырга, кешеләргә яхшылык эшләргә хыяллана. Әтисе кебек врач булыргамы! Әллә укытучымы! Башта Машага укырга кирәк әле, әтисе кебек белем алырга.

Ул бер дә авырмыйча, җитез, елгыр булып, зифа буйлы булып үсеп җитсә дә, әле һаман ситса күлмәктән йөри. Үзе бик тыйнак, кешелекле, көчле характерлы. Бланкның кызлары барысы да музыкага бик сәләтле булалар, әмма Маша унөч яшендә үк инде рояльдә, барысына караганда да тирәнрәк аңлап, рухланыбрак уйный.

Александр Дмитриевич, отставкага чыгып, Кокушкинога күчеп килә.

Янәшә генә ике авыл: берсе татар авылы, икенчесе — рус. Кокушкиноның үзен авыл халкы татарчалап Яңасала дип кенә йөртә.

Әтисе авырулар кабул иткәндә, Маша аңа булыша. Тирә-күрше авылларда аның иптәш кызлары күбәя. Ул аларны укырга-язарга өйрәтә. Бала-чаганы җыеп, рояльдә уйный, җырлар җырларга өйрәтә.

Мария Александровна укытучы булырга хыяллана. Имтиханнарны ул экстерн юлы белән дә тапшырырга мөмкин икәнен белә һәм шулай эшли дә. Имтиханга әзерләнергә дип, апаларына Пензага баргач, ул яшь укытучы Илья Николаевич Ульянов белән таныша. Һәм алар, Кокушкинога кайтып, туй ясыйлар...

...Мария Александровна бөтен вакытын балаларына багышлый. Ләкин гаиләсендә ул командир түгел, дирижер була. Ачуланмыйча, кычкырмыйча, ипләп кенә, ашыкмыйча гына ул балалары белән, хуҗалыгы белән җитәкчелек итә. Куллары аның бервакытта да эштән бушамый. Ул көчәнми генә, интекми генә эшли. Өйдәге бөтен нәрсә куандыра аны. Иртүк торып, тәрәзә пәрдәләрен ачып куя, гөлләргә су сибә. Мич яна башлауга, Илья Николаевич кузгала. Мария Александровна, рояль артына утырып, әкрен генә Шопенны уйный башлый. Балалар музыка уйнаганда уянырга гадәтләнгән. Алар битсулларын юалар, тәннәрен юеш сөлге белән ышкыйлар. Бер-берсенә булыша-булыша киенеп, аш өстәле янына җыелалар.

Әле кон үткәч, кичен, Мария Александровна, кулына шәм тотып, йокларга әзерләнгән балаларын сөеп, һәрберсе белән сөйләшеп чыга. Аннары тагын рояль янына барып утыра. Яисә китап укый.

...Еллар үтә. Инде балалар барысы да укый. Алар инде хәзер укытучылыкка имтихан тоткандагы әниләренә караганда күбрәк беләләр. Бу — ата белән ананың икесенең бергә ирешкән җиңүе. Үзенең хезмәт җимешләрен күрә башлаган Мария Александровнаның кыяфәтендә хәзер нииндер җиңеллек, яктылык барлыкка килә. Аның йөзе ничектер нәфисләнеп, яшәреп китә.



И. ХАНТИМЕРОВ рәсеме.

һәм, һич көтмәгәндә, өскә кинәт авыр кайгы килә: Илья Николаевич вакытсыз дөнья куя... Нишләр соң инде хәзер Мария Александровна берүзе! Ни хәлләр итәр!.. Юк, юк, ул берүзе түгел, балалары белән ул! Алар хакына түзәргә, чыдарга кирәк. Сыгылып төшмәскә, яшәү турында, балаларны кеше итү турында уйларга кирәк.

Аның ышанычы, таянычы — Саша. Талантлы галим, игътибарлы бала, аз сүзле, риясыз дус.

Сашага менә шушындый өметләр баглап торганда, үтергеч хәбәр: Саша патшаны үтерүгә әзерлектә катнашкан!

Бер килсә килә бит...

Ана катгый карарга килә: гомерлек каторга бирсәләр — Саша белән бергә китәргә!

Ләкин, нинди юллар белән генә коткарырга тырышмасыннар, Сашаны үлем җәзасыннан коткарып калып булмый.

Асып үтерелгән улы турында Мария Александровна озак вакытлар буена беркем белән дә сөйләшә алмый. Ул нәкъ шул Петербургта чагындагы кебек булып аның күз алдында кала.

Саша белән бергә кулга алынган Аняны Кокушкинога сөрәләр.

Володя белән Оляның гимназияне тәмамлар вакытлары җитә. Патша властьлары тарафыннан җәзалап үтерелгән кешенең энесенә башкала университеты турында хыялланасы да юк. Димәк, Казанга. Әмма Казан университетына керү дә бик ансат булмый. Әле тегендә, әле монда үтенеч кәгазьләре языла. Җаваплар көтелә... Ниһаять, Володя — Казан университеты студенты!

Әмма студент улы белән беренче сөйләшүләр үк Мария Александровнаның кәефен кыра: гимназиялләрдәге кебек үк, монда да студентлар артыннан шымчылык итәләр, либераль карашлы профессорларны кафедралардан куалар. Бөтен университетларда студентлар чуалышлары бара. Аның дулкыннары Казанга да килеп җитә.

4 декабрьдә, стачка вакытында, башкалар белән бергә Владимир да, шундый авырлык белән алынган студентлык билетын ташлап, университеттан чыга. Ул башкача эшли алмый. Ульяновлар барысы да шундый инде алар.

...Мария Александровна белән Володя, булып үткән хәлләр турында сөйләшә-сөйләшә, төн җиткерәләр. Шул чакны тупас иттереп ишек кагалар. Жандармнар килеп, Володяны алып китәләр. Аның артыннан ишек ябылырга да өлгерми, Мария Александровна, кемгә мөрәҗәгать итәргә, кем исеменә үтенеч кәгазе язарга, дип уйлана башлый; аның эше — балаларына ярдәм итү, аларны бәладән йолу бит. Аның посты шул!

Владимир Ульяновны да Кокушкинога сөрәләр.

1888 елның көзендә Мария Александровна Володяга Казанда яшәргә рөхсәт алуга ирешә. Аңа укуын дәвам иттерергә кирәк, ләкин Казан университетына инде юл ябык. Ниһаять, властьлар рөхсәте белән, Владимир Ильич юридик факультет өчен имтиханнарны экстерн рәвештә Петербург университетында бик яхшы итеп тапшыра. Бу бик зур җиңү иде, әмма язмыш куанырга ирек бирми: Петербургтан, Бестужев курсларында укучы Оляның каты авыруы турында телеграмма килә.

Ана тагын бер баласын соңгы юлга озата...

Владимир Ильич Питерда урнашып кала. Ул үз-үзен сакламый. Салкын тидерә, үпкәсе ялкынсына. Мария Александровна яңадан аның янында, яңадан аны карый, дәвалап аякка бастыра.

Мария Александровнага инде менә 63 яшь тула. Ә ул һаман эшли, акча таба, атлаган саен төрмәгә эләгеп торган балаларына кирәк-ярак илтә, сөргендәге Володяга посылка итеп җибәрергә дип, кирәкле китапларын әзерли, ерак юлда бозылмастай азык-төлек юнәтә...

Ул инде күптән, үз ишләрен артта калдырып, яшьләр арасына, киләчәк буын рәтенә күчкән, үзенең яшьләргә кирәклеген тою бәхетенә ирешкән. Ул инде балаларының эшенә һәм аларның тоткан юлына күптән һәм гомерлеккә инанган. Шулай да аңа һәр сүзен үлчәп сөйләргә, һәр хәрәкәтен чамалап ясарга кирәк. Мәсәлән, чит илдән кайтыр өчен рус кампаниясенә карый торган пароход палубасына менгәч, инде тагын бер мәртәбә улының кочаклап күкрәгенә кыса алмыйсың: монда аны кулга алулары мөмкин. Улың чит җирләрдә калгач, өйдә ансыз бик тә моңсу, бик тә авыр икән шул. Әмма Мария Александровнаны берәү дә бервакытта да көчсез итеп күрми. Аның ябыккан куллары элекке кебек үк ямау ямый, нидер тегә, нидер чигә, нәрсәләрдер кучереп яза... Бу йортта берәү дә эшсез утырырга гадәтләнмәгән.

Ул балалары белән бергә атлый, күңелендәге бөтен нәрсәне алар белән уртаклашырга өйрәнгән. Янында булмаган чакларда, ул аларга һәр көн саен хатлар яза...

Аның балалары унтугыз тапкыр кулга алына, ә ул һәрвакыт алар өчен көрәшә. Кулына төенчек белән азык тотып сөт белән язылган яшерен хатлар тотып, балалары белән күрешергә дип, ул ничә мәртәбәләр төрмә ишек төпләрендә чират көтә...

Балаларының изге көрәштә җиңеп чыгу көненә бу Бөек АНА аз гына барып җитә алмый — 1916 елның 12 июлендә ул 82 нче яшендә вафат була.

(Үзәк матбугатта чыккан материаллардан файдаланып әзерләнде).

С. ИБРАҺИМОВА.
Казан.

Иң матур җыр әниләргә

Минем туган авылым Түбән Өскебаш районнан утыз чакрымнар ераклыкта. Атна саен ук булмаса да, авылга еш кайтырга тырышам. Бу юлы да әнине сагынып, ашкынып кайттым. Әмма мине тагын бикле ишек каршылады. Хәер, мондый хәлгә күнегелгән инде, әни кул кушырып өйдә утыра торган кеше түгел. Я авыл Советы тирәсендәдер, я мәктәптә...

Әниебез, Мөсәббиха Мөбарәкшина, инде лаеклы ялга чыкса да, һаман кеше арасында, һаман җәмәгать эшләре алып бара. Хәзер ул — авылда хатын-кызлар советы председателе.

Әни мәктәптә иде. Бөек Җиңүнең 40 еллыгына багышлап, укучылар зур концерт әзерли. Яшьли ирдән калып, тормышның бар авырлыгын үз иңнәре белән тарткан, балалар тәрбияләгән Г. Фәтхуллина, М. Шәрипова, Н. Хаҗиева, М. Саттарова, Х. Мәгъсумова шикелле апалар исеменә дә атала ул концерт.

Мин әнинең борчуларын аңлыйм. Ул үзе дә унбиш яшеннән эшли башлаган. Сугыш башланганда, аңа бары уналты яшь була. Бу чор кызлары — өлкәннәр белән беррәттән эшләгән, авырлыкны алар белән бергә татыган кызлар.

Әтиебезне, сугыштан кайтуына ук, колхоз председателе итеп сайлаганнар. Әниебез әтинең киңәшчесе дә, ярдәмчесе дә, гаиләнең җылылыгы булган. Аның тырышлыгын, төгәллеген хезмәтендә тиз күреп алганнар. Ул сельпоның баш бухгалтеры дәрәҗәсенә күтәрелгән. Аннары аны авыл Советы председателе итеп сайлап куйдылар. Әни, кайда гына эшләсә дә, үз эшен җиренә җиткереп, намус белән эшләде. Аңа бирелгән дистәләрчә Мактау грамоталары, рәхмәт хатлары шул хакта сөйли. Әниебез В. И. Ленинның тууына 100 еллык юбилейга багышланган һәм «Хезмәт ветераны» медальләре белән бүләкләнде.

...Мин мәктәпкә килеп кергәндә, кечкенә генә кыз әниләргә багышланган җыр җырлый иде. Әйтерсең лә ул минем күңелемдәге уйларны кабатлый...

Гөлсинә САФИНА, КПССның Кукмара райкомы инструкторы.

Биектау районының Кече Рәс авылында Фидаил Гарипов белән бергә уйнап үстек, киләчәккә хыяллар кордык. Әнә шул яшьлек хыяллары безне читкә алып чыгып киттеләр. Фидаил шахтер булды. Мин Казанда калдым. Шахтада эшләгәндә Фидаил Мәдинәгә өйләнде. Тормышын матур итеп башлап җибәрде дустым. Әмма көтмәгәндә бәхетсезлек килде — Фидаил I группа инвалид булып калды. Тормыш сынавының иң авыры Мәдинә өстенә төште. Гаилә Казанга кайтты. Менә уңдүрт ел инде сабый баланы тәрбияләгәндәй Мәдинә Фидаилне тәрбияли.

Тормышта аларның бер мохтаҗлыгы да юк. Барлык мөмкинлекләре булган зур, якты квартира, «Москвич» машинасы... Янында, аны яратып, кадерләп торучы якын кешесе булмаса, авыру кешенең күзенә әйбер күренәмени? Фидаил, бу яктан килгәндә, бик бәхетле. Аның янәшәсендә үзенең олы мәхәббәте белән Мәдинәсе тора. Дустымның шушы бәхетенә шатланудан яздым бу хәбәрне. Мин Мәдинәгә иң олы рәхмәтемне әйтәм.

Шәйхулла ХӘЛИУЛЛИН. Казан шәһәре.

«Таң» колхозында хезмәте белән макталырлык кешеләр күп. Шуларның берсе — Бибинур Хуҗина. Бибинурның яшьлек еллары сугыш чорына туры килә. Мәктәптә укып белем аласы урынга эшләргә кирәк була. Ирләр фронтта, бар эш хатын-кыз җилкәсендә. Уңдүрт яшьлек Бибинур урман кисәргә йөри. Хәер, исән-сау булганда, көчтән килгәнче эшлисең инде. Ә исәнлек бетсә... Бибинурның әнисе авырып, урын өстенә ава. Аягына баса алмый торган әнисен тәрбияләү, мал-туарны карау, колхоз эше һәммәсе-һәммәсе Бибинурның үзенә кала.

Соңрак Бибинур балта остасы булып китте. Һәркөн иртән, кулына пычкы, балта алып, төзелешкә баручы Бибинур Гыйззәтовага хәзер дә сокланмаган кеше юк.

Аларның йорт-җирен, бакчаларын карап туйгысыз. Пенсиядә булса да, һаман эштә, һаман тормыш эчендә.

Ф. НАСИФУЛЛИНА. Әгерҗе районы, Кадыбаш авылы.

Бану апа 30 елга якын җыештыручы булып эшли. Аның тырышлыгы нәтиҗәсендә, безнең башлангыч Биктимер мәктәбе һәрвакыт чиста, җылы, ямьле. Кыш көне дә гөлләр чәчәк атып утыра. Укучылар аның сүзен тыңлыйлар, үзен хөрмәт итәләр. Бану апа балаларга бервакытта да тавышын күтәрми. «Кызым, улым, балам»,— дип кенә эндәшә.

Авырлыкларны күп күргән кеше ул. Яшь-яшь килеш өч бала белән ирдән калды. Аларны әйбәтләп тәрбияләп үстерде. Аталылардан ким булмасын, дип тырышты. Өч баласы да укып әйбәт кешеләр булып чыктылар. Олы улы хәзер Фрунзе шәһәрендә хәрби хезмәттә. Кызы Оренбургта бухгалтер булып эшли. Кече улы зоотехник. Читтән торып институт тәмамлады.

В. ЯКУПОВА, укытучы. Оренбург өлкәсе.


УҢГАННАР УҢЫШКА ИРЕШӘ



Алар алтау. Рәсемдә бишесе (сулдан уңга басканнар): Фәридә Гарәфетдинова, Тәкъмилә Фатыйхова, Зәмилә Андреева, Вера Ефремова, Сәвия Сафиуллина (утыра). Тагын әле Рокыя Гыйниятуллина бар. Бригадирлары — Зәмилә, Казан газ аппаратлары заводының икенче цехында эшлиләр. Обрубщиклар алар, шунда ук үз цехларында коелган детальләрне чистартып торалар. Көч тә, тизлек тә, чисталык та, түгәллек тә сорый торган эш бу.

Бу бердәм, тату коллектив уңганнары көнлек нормаларын даими рәвештә арттырып үтиләр. Еллык планны гадәттә үзләренең профессиональ бәйрәмнәре — нефть һәм газ хезмәткәрләре көненә, сентябрь башына ук башкарып куялар. Бишьеллык планын бригада өч елда, 1983 елның декабрендә үтәде.

Бригадир Зәмилә Андреева — бригада подряды белән эшләүне башлаган кешеләрнең берсе. Аның бригадасының яхшы эшләве коючыларның ничек эшләвенә бәйләнгән. Аларның уңай тәэсире нәтиҗәсендә коючылар да бригадага оешып эшли башладылар.





Кафия Талиповна Сәйфетдинова... Унсигез яшендә, 1953 елда, Казанның 3 нче тегү фабрикасына эшкә килә. Ул бүген дә Татарстан өс киемнәре тегү берләшмәсенең шул фабрикасында эшли. Тегүче. Ясле яшендәгеләрдән алып өлкәннәргә кадәр барлык яшьтәгеләр өчен пальтолар, туннар тегәләр.

«Алтын куллы оста» дигән исеме бар. Күп төрле операцияләрне башкара ала. Аны теләсә кайсы эшкә утыртырга мөмкин. Нәкъ менә Кафия кебекләр булганга күрә, планнар арттырып үтәлә. Цех ай саен уртача йөздән артык кием күбрәк чыгара.

Кафия Сәйфетдинова Яңа елны алты ел ярымлык план үтәп каршылады. Яшь коммунист Асия Хаҗиморатова да аңардан калышмый. Ә Анастасия Михайловна Куляжева күптән инде сигезьеллык план исәбенә эшли. Фабрикада дистәләгән эшче үзләренең бишьеллык планнарын үтәделәр инде.

Цехта, арзанга төшереп, тиз эшиләр. Алар былтыр 4 миллион сумлык киемне Сыйфат билгесе белән тегәргә тиешләр иде. Планны икеләтә диярлек арттырып үтәделәр. Мондый югары сыйфатлы киемне Кафияләр бригадасы тегә. Һәм алар Җиңүнең 40 еллыгына багышланган ярышта фабрикадагы 104 бригада арасында беренче урыннарны алып киләләр.



Галия Шаһимәрдановна Шакирова «Сантехприбор» заводы алдынгысы. Егерме бишенче ел бер үк заводта, бер үк цехта, бер үк участокта, бер үк эштә эшли. Монда андыйлар бер ул гына түгел.

Галия Шаһимәрдәновна һәр бишьеллыкны ударник булып тәмамлый. Бу бишьеллыгын да ул былтыр ук үтәде. Аларның Миндубаев Илһам Зиннәтович җитәкчелегендәге участогы шулай ук йөкләмәләрен алдан үтәп бара. Галия Шакирова эшли торган 3 нче цех тулаем бишьеллыкның соңгы елын былтырның 13 декабрендә үк ачты.

Галия Шакирова кебек алдынгыларның тырышлыгы белән «Сантехприбор» заводы коллективы министрлыкның Күчмә Кызыл Байрагын үз кулында нык тота.



Рузалия Исламова. Казан компрессор заводының җыю цехында эшли. Буяучылар бригадиры. Аның бригадасы ел башына дүрт ел ярымлык план үтәгән иде. Җиңүнең 40 еллыгын алар бишьеллыкка билгеләнгән кадәр эш башкарып каршыларга тырышалар.

Р. ЯКУПОВ фотолары.

ӘРӘМ ИТҮ ЮК

Валентина Ежова бригадасы смена башланганчы ук җыелып бетте. Бригадирга ике эшченең авырганлыгын әйттеләр. Димәк, сменага киеренке туры киләчәк. Гүзәлия Нуриева, Рәмзия Бариева кебек осталар күп. Валентина икешәр кеше эшләргә тиешле участокларга ышанычлы иптәшләреннән берәрне генә куйды, конвейерның «тыгызрак» туры киләчәк урыннарында үзе дә булышырга булды. Әминә Насыйбуллина, Налия Фатыйховалар конвейер тоткарланмаслык итеп урнашалар. Һәм конвейер хәрәкәткә килә. Чираттагы эш көне башланып китә.

Бригадир Ежова үзе дә эштә. Әмма продукциянең сыйфатын өледән-өле күзәтергә вакыт таба ул. Бригада членнарының җитез, бердәм эшләүләрен сокланып күзәтәм.

— Стоп, кызлар!— ди бригадир кинәт.

Конвейер туктап кала. Барысы да Валентина янына җыелалар.

— Күрәсезме, брак,— ди ул, туфли өслегенең бит өлешен күрсәтеп.— Менә бу урында тегелгән юллар читкә чыккан.

Теләсә кем сизә дә торган түгел. Бригадирның үткен күзе күргән. Тегүчеләр дә аның белән килешә.

— Товар катырак шул,— дип аклана брак җибәргән кыз.

Бригадир станокны тикшерә, үзе тегеп карый. Матур итеп тегелгән фигуралы юлларны күргән кызның битенә кызыллык йөгерә. Ежова кычкырмый, ачуланмый, бары тик:

— Мондый товарны тегүебез беренче генә түгел, игътибарлырак кына булырга кирәк,— дип куя.

Яхшы сыйфат белән тегәргә мөмкин булуын күрсәтеп бирүе тәэсир итте бугай. Кабат тикшерүдән соң Ежованың елмаюыннан мин шуны аңлыйм.

«Спартак» аяк киемнәре берләшмәсенең безнең Мамадыш филиалында ярты меңгә якын кеше эшли, күбесе хатынкызлар.

Аяк киемнәре өслекләрен тегүче барлык бригадалар коллектив подряды белән эшли. Яңача эшләүгә күчкәч, эш вакытын югалтулар өч тапкырдан күбрәккә кимеде. Былтыр инде минимумга калды. Эшчеләрнең айлык хезмәт хакы арта килә, хәзер 230 сум алучылар күп. Моңа электр энергиясен, материалларны, чималны экономияләгән өчен бирелә торган өлеш тә керә. Продукцияне күбрәк, яхшы сыйфатлырак җитештергән, чыгымнарны кыскарткан саен, хезмәткә түләү арта бара. Учетчы булганлыктан, миңа болар барысы да яхшы таныш.

Эшчеләрнең бөтен игътибары — конвейерга, үз эшен төгәл һәм тиз үтәүгә бирелгән. Бертөрле хәрәкәт арыта, билгеле, шуңа күрә алар 5-8 минут ял итеп алалар.

Бездә вакытны әрәм-шәрәм итү юк. Шундый бер генә фактны китерәм.

Эшли торган конвейер буйлап барганда, шома күнгә бик матур бизәкләр ясаучы Елена Гавриловага игътибар иттем. Ул кинәт эшеннән туктады да:

— Ватылды,— ди.

Моңа кадәр аяк киемнәре өслеген электрод ярдәмендә бизиләр иде. Бу операцияне үтәү өчен биш пресс кайтарылды. Елена шундый пресcларның берсендә эшли. Аның белән ике-өч сүз алышып та өлгермәдем, көйләүче слесарь А. Ежов, электрик В. Клинов килеп җитте. Алар прессны бик тиз көйләделәр.

Конвейер буйлап атлыйм. Миңзифа Мальцева, Гөлфирә Кирдяшева, Әлфия Хәйруллина, Роза Гарипова, Анна Васильева һәм аларның иптәшләре куллары аша уза-уза, төрле формадагы кечкенә күн кисәкләре зурая бара, матур гына аяк киеме өслеге булып әверелә. Табан гына куясы кала аларга.

— Ә бер пар өслек 24 детальдән тора,— дип аңлата бригадир Анна Кунавина.

Мастер В. Почтарева бригадасы кышкы җылы итекләр тегә. Равия Мөхәммәдиева белән Гүзәлия Мөхәммәтшина иптәшләр теккән кунычларга Нурия Мөстәкыймова «яшен» (замок) урнаштыра. Аннары Надежда Пашина аларның артык-портык җепләрен кисеп ала, бишәр пар итеп капчыкларга тутыра. Табан куйгач, менә дигән җылы итекләр булачаклар.

Бөек Җиңүнең олы юбилее хөрмәтенә ярыш коллективка уңышлар китерә. Хезмәт календаренда өчәр-дүртәр ай алданрак баручылар сафы ишәя. Еллык планны шактый арттырып үтәдек. Беренче сортлы продукция 98,5 процент тәшкил итте. Бу — планда каралганнан 2 процентка күбрәк. 1984 елда хезмәт җитештерүчәнлеге ун процент чамасы үсте.

Әлфинур СӘЙФЕТДИНОВА,
партоешма секретаре урынбасары.
(Журналист К. САФИН язмасында бирелә.)



Н. ТУГАНОВ фотосы.

Кылара белән никахлашканга инде 35 ел узып китте. Шушы гомер эчендә гаиләбездә ун бала дөньяга килде. Әйе, өебез тулы шатлык. Бөтен куанычыбыз шул балаларда.

Улларым Дауыт, Глүс, Юныс һәм кызларым Рәмзия, Әлфия, инде үзләре гаилә корып, «башлы-күзле» булдылар, үзләре бала-чага тәрбияләп үстерәләр. Олы улым Дауыт, Казан авыл хуҗалыгы институтын тәмамлагач, колхозда агроном, аннары партком секретаре булып эшләде. Хәзер дәүләт иминлеге комитеты органнарында хезмәт итә. Хатыны якка да гомуми эш урынында бөтен көчеңне биреп эшләү өчен дәрт бирә. Мин бу яктан бәхетле булдым.

Балалар тәрбияләү бик ансат дисәм, бу ялгыш булыр иде. Чөнки тормышның шактый кыенлыклары бар. Әйе, ишле гаиләнең мәшәкате дә ишле. Берьюлы ун-унике кешегә җитәрлек итеп аш пешерергә кирәк. Кибеткә өс-баш, аяк киемнәре кайтса да, бер-ике белән генә канәгатьләнеп кала алмыйсың. Шундый бер вакыйга хәтергә уелып калган. Көннәрдән бер көнне мин Рәмзиягә кофта алып кайттым. Рәмзия аны көн буе салмады. Икенче көнне әнисеннән

Әлбәттә, икесенә дә бик кыен була. Шулай да, әни өч ай курста бик яхшы укып кайта һәм шул елда ук бригадир булып эшли башлый. Районда алдынгы бригадир буларак, колхозчыларның беренче республика съездында катнаша. 18 ел рәттән әни бригадирлык хезмәтен башкарды. Ул вакытта бригадирлык хезмәтенең авырлыгын хәзерге яшьләр күз алдына да китерә алмыйлар. Ул вакытта колхозчы җәй айларында иртәнге сәгать өч тулганда эшкә китте, кичке 9-10 нарда гына эштән кайтты. Ә бригадирга, иң башлап торып, эшкә әйтергә кирәк, иң соңлап кайтырга кирәк. Йорт-

ӨЙ ТУЛЫ ШАТЛЫК

да югары белемле укытучы. Балаларын алар хезмәт яратырга өйрәтеп үстерәләр. Олы тормыш юлына баскан улларыбыз һәм кызларыбыз үзләренә һөнәр сайладылар, махсус урта, югары белем алдылар. Глүс, мәсәлән, диңгезне яратты, хәзер ул Камчаткада. Рәмзия — өлкән бухгалтер. Әлфия — медсестра. Юныс Актаныш районының ГАИ начальнигы булып эшли. Газинур, Совет Армиясендә хезмәтен үтәп, хәзер юрист булырга әзерләнә. Ә Илшатыбыз Совет Армиясе сафларында, илебез сагында уяу хезмәт итә. Игезәк балаларыбыз Фәрит белән Рәшит 8 класста, төпчек кызыбыз Гөлназ 5 класста укыйлар. Алар да фәннәрне үзләштерүдә, хезмәт күнекмәләре алуда сынатмыйлар — һәр яктан үрнәк укучылар булып саналалар.

Шатлыкларымны барлыйм, истәлекләремне яңартам. Гаилә коргач, тормыштагы иң зур шатлыгым беренче баланы кулга алу булды... Бүген инде, тормыш тәҗрибәмнән чыгып, шуны әйтергә тиешмен: гаиләдә беренче балага, аны тәрбияләүгә зур игътибар итәргә кирәк! Чөнки калган балалар һәрберсе өлкән баладан үрнәк алырга, аңа охшарга тырышып үсәләр. Беренче баланы тәрбияләүдә әби кешенең ярдәме дә кирәк. Ләкин кайбер киленнәр, үзләренең бианай булачагын уйламыйча, өлкән кешеләрне кыерсытучан булалар. Тормышта зур ялгышлык җибәрелә. Безнең беренче балабыз Дауыт әбисе янында үсте. Әйбәт тәрбияле булды. Калган балаларыбыз барысы да аңа охшарга тырышып үстеләр. Хәзерге көнгә кадәр начар гадәтләре күренми. Билгеле, ана кешенең баланы эшкә өйрәтеп үстерүе тормышта зарури мәсьәлә. Хатынымның хезмәте бу өлкәдә аеруча зур. Минем озак еллар җитәкчелек эшендә эшләвемдә дә аның ярдәме зур булды. Әгәр ул сабыр холыклы, түземле булмаса, тормышыбызда көйсезлекләр булуы бик ихтимал иде. Чөнки колхоз председателенең төгәл билгеләнгән эш сәгате юк. Аны булдырып та булмый. Кайчагында ярты төнгә кадәр эшләргә туры килә. Кайвакытта бик иртә дә торасың. Иртәнге сәгать 2-3 ләрдә эш башланган була. Әгәр тормыш иптәшең сине аңламыйча, тавыш чыгарып каршы алса, ике якка да бик күңелсез булыр иде. Эшләү сәләте дә кимер иде. Тормыш иптәшеңнең яхшы булуы һәр ике

рөхсәт сорап, 2-3 сәгатькә генә кия дә, әйбәтләп төреп кире китереп бирә. «Нәрсә булды, кызым, ошамадымыни?» — ди әнисе. «Әлфиягә дә әйбәт килеш калсын, аның да киясе бар бит аны», — дип җавап бирә кызыбыз.

Менә шулай... Өлкән балалар үзләре кигән киемне чиста һәм пөхтә килеш сеңелкәш-энекәшләренә калдыру өчен тырышалар. Кешенең матурлыгы киемдә түгеллеген, кеше эше белән матур булырга тиешлеген аңлап үсәләр.

Дөрес, әниләренә нәниләр аякка басканчы авырга туры килде. Ә тәпи йөри башлауларына малайлар да, кызлар да бер-берсенә булыша торган булып киттеләр. Дөресен әйткәндә, алар берберсен карап үстерделәр. Тагын шунысы бар: колхоз җитәкчесе балалары булсалар да, алар башкалардан бернәрсә белән дә аерылып тормадылар. Өс-баш киемнәре дә гади иде. Шул гади киемнәрне чиста итеп, зәвыклы итеп кия белделәр. Каникул чорында алар колхозда эшләделәр. Моның белән балаларыбыз хезмәтнең тәмен, әйбернең кадерен белергә өйрәнеп үстеләр.

Балалар тәрбияләүдә әти кешенең роле ничек булырга тиеш соң?

Бала тәрбияләүдә үз әти-әниемнең үрнәге минем өчен өлге булды. Без гаиләдә дүрт бала үстек. Әтиебез миңа 10 яшь тулганчы ук дөнья куйды һәм без әниебез тәрбиясендә калдык.

Әтиебез бик таза, зур гәүдәле, көчле кеше иде. Япон һәм Герман (беренче бөтендөнья сугышы) сугышларында катнашып, армиядә күп гомерен үткәргән, дөньяның ачысын татыган, тормышның кадерен белергә өйрәнгән, бик эшчән кеше иде. Үзе бик күп һөнәр иясе: балта остасы, агач эше остасы һәм тимерче иде. Ул исән чакта, без бик яхшы яши идек. Алдынгы фикерле кеше иде ул. Колхозлашу башлангач та безнең семья беренчеләрдән булып колхозга кергән.

Әти әнидән 30 яшькә өлкән иде. Гаиләдә өч бала булгач, әти әнигә болай ди: «Бу балаларны тәрбияләү синең өстә кала инде, хәзерге яңа тормышка укыган кешеләр кирәк, син гарәпчә азрак укый-яза беләсең, бездән җиде чакрымда гына бригадирлар хәзерләү курсы ачыла икән, шунда барып укып кайт. Мин балаларны да карармын, дөньяны да күтәрмен, курыкма», — ди.

та эшләү өчен әнинең һич тә вакыты калмый иде. Дөнья көтү безнең өскә төште. Шулай итеп, без бик бәләкәй чактан ук хезмәтне белеп үстек. Һәм без ким-хур булмадык. Киресенчә, барыбыз да — сау-сәламәтләр, эш кешеләре. Бер энем балта остасы. Шулай ук зур гаилә башлыгы — 7 бала үстерделәр. Бер сеңелем инде пенсия яшендә, бик яхшы яши.

Әниебезне һәр колхозчы турылыклы, намуслы хезмәте өчен яратты. Аны үзенең әнисе кебек күрде. Моны без тоеп үстек. Һәрчак һәм һәрнәрсәдә намуслы хезмәт үрнәге күрсәтергә аңардан өйрәндек. Димәк, гаиләдә бала өлкәннәрнең шәхси, тырыш хезмәт үрнәгендә тәрбияләнә икән. Иң мөһиме: ата-ананың сүзе эштән аерылмаска тиеш. Шул чакта гына бала гаиләдә кыенлыкларны җиңәргә чыныгып үсә, җиңел тормышка өйрәнми, үзенең фидакарь хезмәте белән яшәргә әзерләнә.

Мин үзем, инде әйткәнемчә, авылда, җир анага гашыйк булып үстем. Әнием Мәптүха, элекке «Алга» колхозында тәҗрибәле бригадирларның берсе буларак (хәзер Чирү авылы «Игенче» колхозына керә), миңа игенче һөнәрен, икмәк үстерү серләрен өйрәтергә тырышты. Шуңа күрә мин, кече яшьтән үк, әнием кебек, ил байлыгы — ашлык үстерү серләренә төшенергә, җир докторы — агроном профессиясен үзләштерергә хыялландым. Һәм, Куҗәкә җидееллык мәктәбен тәмамлагач та, туган колхозыбызда агротехник булып эшли башладым. 1943 елның январе башында илебез азатлыгын саклау өчен көрәшкә киттем һәм Бөек Җиңү яулап, 1947 елда туган авылыма, тыныч хезмәт фронтына кайттым.

«Алга» колхозында төрле эштә эшләдем, аннары бригадир һәм председатель хезмәтләрен башкардым. Казандагы колхоз председательләре хәзерли торган өч еллык мәктәпне тәмамлап, «Ленин бүләге» (хәзер Мөслим районына керә) колхозында председатель булып эшләдем. Читтән торып, Казан авыл хуҗалыгы институтын тәмамладым. Инде 20 еллап яраткан профессиям буенча «Таулар» колхозында председатель булып эшлим. Фидакарь хезмәтемнең якты символы булып, күкрәгемдә хөкүмәтебезнең күп кенә бүләкләре балкый.

Мактанып әйтүем түгел, мине тормыш-

та берәү дә иркәләмәде, үземә һәм коллектив членнарына, беренче чиратта, колхоз партия оешмасына һәм коммунистларга таянып хезмәттә җиңү артыннан җиңү яуладым. Гаилә членнарым: кызлар-улларыбызга да тормышта путевка сайлауда безнең, ягъни әти-әниләренең шәхси тормышы һәм хезмәте төп үрнәк булгандыр, дип саныйм.

Без — Камалетдиновлар — бүгенге Совет чынбарлыгының бәхетле язмыш хуҗалары. Октябрь кояшының җылысын тоеп яшибез һәм киләчәкне актив тәэсүче яшьләр үстерәбез. Әйе, Коммунистлар партиясе һәм совет хөкүмәтенең кайгыртучанлыгы безнең гаилә мисалында гына да әнә ничек чагыла!

Мин күп балалы гаилә башлыгы булуым белән үземне бик бәхетле саныйм. Чөнки өй тулы шатлык — өй тулы балалар.

КПСС Үзәк комитеты Генеральный секретаре, СССР Верховный Советы Президиумы председателе иптәш К. У. Черненко Мәскәүнең «Урак һәм чүкеч» металлургия заводы эшчеләре белән очрашуда болай диде: «...Дәһшәтле сугыш елларында ул малай килеш станок артына баскан, уналты яшендә бригадир булган, ә егерме биш яшенә таба цех өчен җавап биргән, мондый мәктәпне бер нәрсә белән дә алыштырырга мөмкин түгел».

Бу сүзләр беркайчан да минем хәтердән чыкмый. Бу сүзләр миңа нәкъ менә хезмәт, Ватаныбыз файдасына фидакарь хезмәт итәргә чакыручы девиз булып яңгырый һәм гаилә членнарын шушы үрнәктә хәзерләргә өйрәтә.

Инсаф КАМАЛЕТДИНОВ,
«Таулар» колхозы председателе, Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены кавалеры, КПССның Татарстан өлкә комитеты члены.
Актаныш районы.

Укучыларыбыз игътибарына анкета тәкъдим итәбез.

1. Гаиләдәге иң зур уңышыгыз һәм кимчелегегез нидән гыйбарәт:
- **балалар тәрбияләүдә;**
- **иргә мөнәсәбәтегездә;**
- **гаиләдәге өлкәннәргә мөнәсәбәтегездә!**

2. Балаларыгызда нинди сыйфатлар тәрбияләргә тырышасыз?

3. Ир-атларда нинди сыйфатлар өстенлек итәргә тиеш дип саныйсыз?

Анкетага җавап биргәндә ничә яшьтә, гаиләмеле, кем булып эшләвегез, ничә балагыз барын языгыз, адресыгыз һәм фамилиягезне куюу мәҗбүри түгел.

ХАТЫН-КЫЗЛАР СОВЕТЫ



Рәсемдә: хатын-кызлар советы үзенең активы белән киңәшкә җыелган. Уртада советның председателе — Фәридә Сәүбәновна Шәфигуллина.

Бу авылга ул моннан ун ел элек килгән иде. Мәктәптә тарих укытты, хатын-кызлар советы председателе дә итеп сайладылар үзен. һәм менә ун ел инде бу эшен искиткеч яратып башкара ул. Хатын-кызларның хезмәт, көнкүреш һәм ял шартларын яхшырту максатында совет планын да колхоз идарәсе, партия оешмасы белән берлектә төзи. Җиде кешедән торган советның һәр членының үз вазифасы бар. Клуб методисты Ләйсирә Сабирова, мәсәлән, культура-агарту эшләрен алып бара, алдынгы чөгендер игүче, һәрвакыт гадел һәм төпле фикерле Әлфия Маннапова торак-көнкүреш мәсьәләләрен тикшерә, балалар бакчасында эшләүче Нәзирә Дәүләтшина балалар һәм үсмерләр белән эшли, медицина хезмәткәре Рәйхана Гомәрова исә хатын-кызларның хезмәтен һәм сәламәтлеген саклау секциясен җитәкли. Председательнең, ягъни Фәридә иптәш Шәфигуллинаның урынбасар вазифасын колхозның һәр кешесен белә торган кадрлар бүлеге инспекторы Фирдәвес Әхтәриева башкара.

Хатын-кызлар советының күп төрле эшләре арасында хезмәт тәрбиясе үзәк урында тора. Узган ел, мәсәлән, совет тәкъдиме белән, колхоз шикәр чөгендерен подряд ысулы белән иккән һәм эшкәрткән иде. Бу эштә совет членнары үзләре үк үрнәк тә күрсәттеләр. Мәдинә Нигъмәтуллина, Флера Кавиевалар, мәсәлән, меңәр центнер чөгендер тапшырдылар. һәм узган елда ук «Ракета» колхозы, Апас районында беренче булып, бу төр культура игү һәм дәүләткә тапшыруның бишьеллык планын үтәп макталды.

Идеология эшләре белән бергәттән, пенсиягә озату кебек тантана-бәйрәмнәрне дә хатын-кызлар советы оештыра. Былтыр, мәсәлән, олы бәйрәм ясап, зур-зур бүләкләр биреп сигез колхозчыны пенсиягә озаттылар. Быел исә клуб бинасында берьюлы биш гаиләнең көмеш туен бәйрәм иткәннәр. «Гаилә: ир-ат, хатын-кыз» исеме белән үткәрелгән кичәдә, мәсәлән, ир-атларның гаиләдәге позициясе йомшару кебек бүгенге көн проблемалары күтәрелгән, зур сөйләшү булган.

Бөек Җиңүебезнең 40 еллыгына багышлап, әле шушы көннәрдә генә хатын-кызлар советы тагын зур бер кичә үткәрде. Бу кичәгә ирләре сугышта үлгән хатыннар гына чакырылды. Моңга-сагышка уратылган бу хатирә-кичәдә дә бүгенге көн матурлыгына мәдхия җырланды. Кичәнең девизы: Җир йөзенә — тынычлык!— иде.

ГОРУРЛЫГЫБЫЗ АЛАР

«Бөек Ватан сугышында фашист илбасарларга каршы Икенче фронтны союзниклар түгел, тылдагы хатын-кызларыбыз ачты. Сугышчыларыбызны азык-төлек, кием-салым белән алар тәэмин итте, изге теләкләр белән алар рухландырып торды». Бу сүзләрне Ленинград язучысы һәм галим, дәүләт премиясе лауреаты, Ватан сугышы ветераны Федор Абрамовтан ишетеп, миллионлаган телевизор тамашачылары белән бердәм хуплаган идек. Чөнки әби-апаларның, сеңелләрнең тылда әнә шулай тырышып эшләүләренең бер шаһиты үзем идем. Ул көннәрдә, авыру буларак тылда калып, Кукмара район газетасында редактор булып эшләдем. Ат җигеп тә, җәяүләп тә бөтен район колхозларын иңләдем.

Әле дә истә: мең тугыз йөз кырык дүртенче елның язы иде. Кыр эшләренең барышы белән танышу өчен шул чактагы «Алга» колхозы, Туеш авылына юл тоттым. Күктә тургайлар сайравына трактор гөрелтесе кушыла. Әнә, каршыга «СТЗ» маркалы тракторы килә. Руль артында кызыл яулык чөйгән алсу йөзле, кара кашлы яшь кыз. Ул — Кукмара МТСының алдынгы механизаторы Габидә Габделхаева. Азга гына туктатып, сеңелнең эше белән танышам.

— Кичә сөрү нормамны 150 процентка үтәгән идем. Бүген тагын да тырышыбрак эшлим әле,— ди ул шатланып.

Икенче басу түреннән «У-2» тракторы белән Хөршит Нургалиева төшеп килә. Норма буенча өч гектар ярым урынына көн саен алтышар гектар сөрә уңган кыз. Тракторчы Фәүзия Закирова эшли торган агрегат янына да тукталабыз. Ул да алдынгылар сафында, стена газетасында «Уңганыбыз Фәүзия» дигән мәкалә язылган.

Әйе, дәһшәтле сугыш елларында Кукмара МТСында йөздән артык механизатор кыз эшләде. «Фронт өчен, бөтенесе дә дошманны җиңү өчен!»— дигән сугышчан девиз белән эшләделәр алар.

Әле дә хәтеремдә: Яниль МТСы механизаторлары һәр елны өлкә күләмендәге социалистик ярышта беренчелекне яулыйлар иде. 1944 елны да язгы чәчү һәм игеннәрне урып-җыю планнарын кыска срокта арттырып үтәүгә ирештеләр алар. Шул елны әлеге МТСның комсомолка Сәгура Мостафина җитәкләгән хатын-кызлар бригадасы, «У-2» маркалы һәр трактор белән планнан тыш 220 гектар җир сөреп, комсомол-яшьләр трактор бригадаларының Бөтенсоюз ярышында өченче урынны яулады. Бу МТС тракторчылары Нәсихә Мөхәрләмова, Наталья Игнатьева, Бикә Гыйззәтуллина һәм Разия Закированың исемнәрен дә Мактау тактасында еш күрә идек. Комбайнчы Рәшидә Һадиева һәр елны 400 гектар мәйданның игенен урып-җыю иде.

Ул вакыт техника җитми иде. Шунлыктан атлардан киң файдаланылды. Берүк вакытта күп кенә колхозчылар шәхси хуҗалыкларындагы сыерлары белән дә җир тырмалау, кырга орлык ташу кебек эшләрдә булыштылар. Сыерларын җигеп, дәүләт амбарларына ашлык ташыдылар. Район газетасының шул чорда чыккан бер санында Купка авылы колхозчысы Гаделбану Хәкимуллинаның, үз сыерын җигеп, элеваторга көн саен өчәр центнерга якын ашлык илтүе хакында сөйләнә.

Авыр сугыш еллары хуҗалыкны какшатты. Күп кенә колхозларның чәчәргә орлыгы җитми иде. Монда да колхозчылар ярдәмгә килде. Пычак авылының өч фронтовик анасы коммунист Хәерниса апа Нуриева, колхозга чәчүлек өчен үз хуҗалыгындагы запастан 100 пот ашлык һәм бәрәңге биреп, беренче булып үрнәк күрсәтте. Аның патриотик чакыруына кушылып, башка колхозчылар да орлык туплауда актив катнаштылар. Стаханов исемендәге колхоз хезмәтчәннәре Ф. Корбангалиева — үз хуҗалыгыннан орлык фондына 27 пот, Р. Фазылҗанов һәм Ю. Әхмәтҗановлар 60-70 пот ашлык һәм бәрәңге тапшырдылар. Нәтиҗәдә район буенча колхозларның орлык фондына меңнәрчә центнер чәчүлек материал җыелды. Партия өлкә комитеты кукмаралыларның бу башлангычын яхшы дип тапты. Шуннан патриотик хәрәкәт бөтен республикабызда киң колач җәйде.

Игенчеләрнең тырышлыгы нәтиҗәсендә, күпчелек колхозлар тотрыклы югары уңыш үстерделәр. Стаханов исемендәге колхозның Н. Юсупова һәм З. Сабирҗанова җитәкләгән звенолары бөртеклеләрнең һәр гектарыннан 15-16 центнер уңыш җыеп алдылар. Бу хуҗалык ул елны игеннәр урып-җыюны сентябрьнең беренче атнасында тәгәлләдә, ашлык хәзерләү планын 9 сентябрьгә арттырып үтәде.

«Әсәнбаш» колхозы эшчәннәре дә ашлык өчен зур тырышлык куйдылар. Бу хуҗалык 1944 елда дәүләткә ашлыкны сугышка кадәрге 1940 елгыдан ике тапкыр күбрәк тапшырды. Шул елны партия өлкә комитеты беренче секретаре иптәш З. Моратов районның ашлык хәзерләү планнарын арттырып үтәгән күп кенә колхозларның хезмәтчәннәрен котлап телеграмма җибәрде.

Район хезмәтчәннәре, фашизмны тар-мар итүгә лаеклы өлеш кертергә омтылып, Кызыл Армиягә һәрьяклап булышлык күрсәттеләр. Алар «Кукмара колхозчысы» исемле сугышчан самолетлар төзү өчен 1 миллион 200 мең сум акча җыеп тапшырдылар. «Коммунизмга» колхозы умартачысы Рәшит бабай Латыйпов үзе генә дә бу фондка 50 мең сум акча кертте. Район хезмәтчәннәренең бу патриотик эше өчен Верховный Башкомандующийдан рәхмәт телеграммасы килде. Шулай ук кукмаралылар хәрәкәттәге армия сугышчылары өчен җылы киемнәр җибәреп тә фронтка булышлык күрсәттеләр.

Бу язмада Кукмара районы хезмәт ияләренең сугышның бер елы эчендәге кайбер эшләре турында гына сөйләнә. Алар исә Бөек Ватан сугышының башыннан ахырына кадәр тылда әнә шулай героик хезмәт үрнәкләре күрсәтеп эшләделәр, Бөек Җиңүгә өлеш керттеләр. Район партия оешмасы аларны сөекле Ватаныбыз хакына фидакарь хезмәткә, данлы эшләргә рухландырды. Ә бу данлы эшләрнең алгы сызыгында һәрчак коммунистлар булдылар.

Партия активы массаларның тырышлыгын Ватан алдындагы изге бурычларын үтәүгә туплау буенча зур оештыру-тәрбия эше алып барды. Шул елларда КПСС райкомының пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире булып эшләгән Х. Сәгыйдуллина, райком инструкторлары М. Абдуллина, М. Әмирханова хәзер лаеклы ялдагы иптәшләр үзләрен ялкынлы пропагандистлар, оештыручылар итеп таныттылар.

Кукмара районы хезмәтчәннәре, героик традицияләргә турылыклы булып, иҗади тыныч төзелеш өлкәсендә дә зур уңышлар яулыйлар. Сугыштан соңгы чорда район халык хуҗалыгы торгызылды, тагын да алга китте. Авыл хуҗалыгы производствосы аеруча уңышлы үсә, колхозлар экономикасы елдан-ел ныгый.

Хәзер дә хатын-кызлар — авылда зур көч. Әйтик, терлекчелектә эшләүчеләрнең күпчелеген алар тәшкил итә. Хуҗалыкның бу тармагында күркәм нәтиҗәләргә ирешелә. Узган ел, мәсәлән, район буенча һәр сыердан уртача 3 мең килограммнан артык сөт савып алынды. Җитмештән артык савымчы бу күрсәткечне 3500-4500 килограммга җиткерде. «Восток» колхозы терлекчеләре коммунист М. Хәмидуллина һәм комсомолка Ф. Закировалар исә һәр сыердан елына 4656-4800 килограмм сөт савып алдылар.

Быелгы план һәм социалистик йөкләмәләрне үтәү өчен көрәштә дә зур уңышлар яулана. Авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерү арта.

Районда Бөек Җиңүнең 40 еллыгы хөрмәтенә ярыш торган саен киңрәк җәелә бара. Һәр коллектив данлыклы датаны хезмәт бүләкләре белән каршыларга омтыла. «Урал» колхозы ферма эшчәннәре ярышка тон бирә. Бу хуҗалык терлекчелек продукциясе хәзерләү буенча унберенче бишьеллыкның дүрт елы планын узган елның 1 маена ук арттырып үтәде. Уралылар, дәүләткә ит сатуның бишьеллык планын узган ел Октябрь бәйрәменә үтәргә йөкләмә алып, районның барлык ферма эшчәннәрен ярышка чакырдылар. Аларның башлангычы киң яклау тапты. «Новая жизнь», «Коммунизмга», «Россия», «Дружба», «Восток», «Маяк» колхозларының хезмәтчәннәре бишьеллык планны срогыннан элек үтәү өчен көрәштә аеруча әйбәт нәтиҗәләргә ирештеләр.

Ярми ГАЙНУЛЛИН,
СССР Журналистлар Союзы члены, персональ пенсионер.



Болар — сугыш елларында яраланган сугышчыларны аякка бастыру өчен бөтен көчләрен биргән шәфкать туташлары, Рафика артта басып тора.

1945 ★ 1985
РАФИКА АПА СӨЙЛИ

Район үзәге — Чүпрәленең Совет урамындагы гадәти бер йорты. Бу агач өй янындагы кечкенә генә бакчада кура җиләге куаклары һәм ике каен үсеп утыра. Бу өйдә хезмәт һәм сугыш ветераны Рафика Садриевна Низамова яши. Ишекне яшьләрчә җитез хәрәкәтле, мөләем гына хатын ачты.

Без Рафика апа янына аның фронт юлларын искә төшерүен үтенеп килдек.

— Сүзне шуннан башлыйк,— дип сөйләде ветеран.— Сугышның беренче көннәреннән үк шинель киюче Чүпрәле кызлары күп булды. Безнең авылдан — Яңа Чүпрәледән шофер Әминә Сәләхова хакында райондашларыбыз беләләр инде. Ул сугышта да шофер иде, медальләр белән бүләкләнде. Сугыштан соң озак еллар Чүпрәле МТСында, аннары «Сельхозтехника»ның район берләшмәсендә шофер булып эшләде. Ленин орденын шул вакытта алды.

Район элемтә бүлегеннән почтальон Фәүзия Насыйбуллина — Иске Чүпрәледән сугышка киткән кызларның берсе. Ул 1942 елдан 1944 елның сентябренә кадәр артиллерия полкында телефонистка булып хезмәт итте. Безнең Чүпрәле районы авылларыннан — Иске Шәйморзадан Фәридә Шәмсетдинова, Зәйтүнә Җаббарова, Яңа Чокалыдан Халидә Хәлиуллина, Хәнифә Җамалетдинова, Чепкас-Илмәттән Зәделгаян Гыйниятуллина, Шлангыдан Мөхлисә Юсупова, Иске Чокалыдан Мәһирә Айзәтуллова, Кече Чынлыдан Фәүзия Хәснетдинова, Убидан Анна Ирюкова, Ольга Адьютантова, Чуваш Чүпрәлесеннән Галина Скворцова, Саплыктан Мария Матросова, Анна Казакова, Матактан Валентина Мадюкина, Яңа Задурдан Сәкинә Җамалетдинова һәм башка кызларыбыз хәрәкәттәге армия сафларында явыз дошманны җиңүгә үзләреннән өлеш керттеләр.

Мин үзем Казанда җиңел промышленность техникумын бетереп, Кукмарада киез итек фабрикасында эшләдем. Без фронтка киез итекләр озата идек. Шунда 1941—1943 елларда медицина сестралары хәзерләүче мәктәптә укыдым. Шуннан 1943 елда сугышка киттем. Фронт юлларын мин Литвадан башладым һәм сугыш беткәнче кыр госпитальләрендә шәфкать туташы булып хезмәт иттем.

Аннары Ерак Көнчыгышта милитаристик Японияга каршы сугышка киттем. 1945 елның октябрь-ноябрь айларында госпитальдә хезмәт иттем.

Рафика Садриевна безгә фотолар һәм фронт документларын, үзе язган шигырьләрен дә күрсәтте. Менә бер фотода сигез хәрби кеше: офицерлар, солдатлар һәм биш кыз — медицина хезмәткәрләре. Дәваланганнан соң хәрбиләр үз частьларына китәр алдыннан рәсемгә төшкәннәр. Часть командованиесе имзасы белән бирелгән кадерле документ. Анда: «Иптәш Низамова Рафика Садриевна! Верховный Башкомандующий, Советлар Союзы Генералиссимусы иптәш Сталин 1945 ел 23 августтагы 372 номерлы приказы белән Ерак Көнчыгышта японнар белән сугышта уңышлы сугышчан хәрәкәтләре өчен частьның барлык личный составына, шул исәптән Сезгә дә — сугышта актив катнашучыгыа рәхмәт белдерде»,— дип язылган.

Бөек Ватан сугышы ветераннары, элеккечә, сафта. Алар башкача булдыра алмыйлар, чөнки бүгенге дөнья тыныч түгел. Безгә яңадан сугыш белән яныйлар. Әмма без белеп торабыз: Ватаныбыз никадәр ныграк булса, сугышны булдырмау гарантиясе дә шулкадәр зуррак. Безнең һәркайсыбыздан тик бер нәрсә — намус белән эшләү таләп ителә.

«Без, ветераннар, совет халкының данлы традицияләрен киләчәктә дә арттырырбыз, яшьләрне шул традицияләр рухында тәрбиялләрбез, дип ышандырабыз. Совет иле бөтен дөньяда тынычлык таянычы булсын өчен, үзебезнә соңгы сулышыбызга кадәр кызганмабыз.

Мин туган авылым Яңа Чүпрәлегә 1946 елның көзендә кайттым. 1947 елның 15 июненнән район больницасында эшли башладым. Сугыштан соңгы елларда биредә фронттагыдан җиңел түгел иде.

Мин бүген дә шул больницаның туберкулезга каршы көрәш диспансерында эшлим».

Рафика апа шул коллективның профоргы, ветераннарның район Советы члены. Ул гармунда һәм пианинода уйный, җырлый һәм бии. Бу осталыкларын ул яшереп тормый, больница үзешчәннәре чыгышларында бик еш катнаша.

Рафика апа ике бала үстерде. Олы кызы Әлфия — В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан Дәүләт университетын тәмамлады, фәнни-тикшеренү институтында эшли, ире белән Казанда тора. Гүзәл дә тормышка чыкты. Ульяновск шәһәрендә яшиләр. Хәзер Рафика апа аларның балаларын — оныкларын сагынып каршы ала. Үзләре югында Әлфия һәм Гүзәл хөрмәтенә тәрәзә каршысына утыртылган ике каенга карый. Карый да, дәфтәренә шигырь юллары язып куя:

«Әкрен генә искән таң җилләре,
Тәрәзәңне барып чиртерләр,
Чиртерләр дә алар, күңелемдәге
Сәламемне сезгә илтерләр».

Р. НИЗАМОВ.
Чүпрәле.



Рафика апа кызлары Әлфия һәм Гүзәл, оныгы Ләйлә белән.

Утлы еллар истәлеге

Билгеләнгән план буенча, Галимнәр йортына репетициягә килдек. 1941 нче елның 23 нче июнь көне иде бу. Галимнәр йорты бөтенләй үзгәргән: гадәттә, музыкантлар килүгә тезелеп куела торган пультлар да, урындыклар да юк. Аларны коридорга чыгарып, бер почмакка өеп куйганнар. Тамаша залы бушатылган. Һәм без дә ул көнне барлык бүлмәләрдән җиһазларны чыгару, Галимнәр йортын бушату белән уздырдык. Бинаны эвакуация белән килүчеләр өчен хәзерлиләр иде.

Икенче көнне безне Татарстан Халык Комиссарлары Советы каршындагы сәнгать эшләре идарәсенең приказы белән таныштырдылар... Бик күп ирләрнең армиягә чакырылуы уңае белән, ансамбль составында нибары егерме генә кеше калып, ул хатын-кызларның җыр һәм бию ансамбленә әверелде. Оркестрлар таратылды. Ансамбльне авылларга гастрольгә җибәрү өчен хәзерлек башланды.

Июльнең беренче көннәрендә без инде авылларда идек. Җитәкчебез — хормейстер И. В. Грекулов, баянчыбыз — Габдулла Халитов. Программабызда — татар халык көйләре. Кайсы гына авылга барып кермик — йөрәк кысыла, күңел әрни. Урамнарда беркемне очратмыйбыз, йортларга керсәк — күз яше, ыңгырашу. Юлларда сугышка китеп баручы төркем-төркем ирләр, аларны озата баручы хатын-кызлар, балалар очрый. Тагын күз яше.

Һай, бу кайгы-хәсрәтле көннәрдә кем генә килер икән безнең концертларга, дибез. Борчылабыз. Уңайсызланабыз. Әмма кичләрен халык клубка җыела. Иң элек сәхнәгә колхоз, авыл Советы җитәкчеләре күтәрелә. Алар дулкынланып халыкка мөрәҗәгать итәләр: «Илебез көчле. Ул җиңәчәк. Җиңүне тизләтү өчен тырыш хезмәт, ныклык, сабырлык кирәк. Бертугандай, бөтен көчне туплап, бергә эшлик»,— дип, алар авылдашларын эшкә, нык рухлы булырга өндиләр.

Шундый эчтәлекле сүзләрдән соң, безнең концерт башлана. Ул чыгышларны концерт-митинг дип атыйсым килә. Әнә шундый өндәү-чакырудан торган митинг-концертларыбыз сентябрьгә кадәр дәвам иттеләр. Ә көндезләрен без кырда, эштә булдык. Дүрт ел буе без җәен дә, кышын да авылларга гастрольләргә чыктык. Дүрт ел буе авылларда көндезләрен эштә булдык. Бәрәңге дә утадык, аны җыярга да булыштык. Маллар өчен үлән дә чаптык, көлтә дә җыештык. Ә кышларын авыл яшьләренә репертуарыбыздагы җырларны өйрәттек.

1941 нче елның кышы аеруча хәтердә калган. Казанга кайткан араларда, чатлама суык, кар-буран астында,



без военкоматлар янында, вокзалларда фронтка китүчеләр өчен ачык машина өстендә концерт күлмәкләреннән генә чыгыш ясый идек. Аннары көннәребез госпитальләрдә үтә иде. Репетициягә җыелабыз, репетиция бетүгә — госпитальләргә юл тотабыз. Кайбер көнне безне унберәр, уникешәр госпитальгә җибәрәләр, кайчакта бер-ике генә госпитальдә концерт бирсәк тә хәлдән таеп кайтабыз. Каты яраланганнар белән очрашу безне тетрәндерә, хәлебезне ала иде. Көннәрнең берендә без Казан авыл хуҗалыгы институтына урнашкан госпитальгә килдек. Беренче булып сәхнәгә мин чыктым. Җырлый башладым. Күзем беренче сафта утыручыларга төште. Сәхнә алдында утыручыларның берсенең дә йөзе күренми. Марля белән башлары уралган, йөз-битләре капланган. Күзләре ялтырамаса, баш ничектер сәер генә селкенеп китмәсә, аны бит-йөз дип уйламыйсың. Бу күренеш минем аңымны алды. Башым әйләнеп китте. Күз алларым караңгыланды. Җырлый



алмыйча, сәхнәдән елап чыгып китәргә мәҗбүр булдым. Аннан соң да, дүрт ел буена госпитальләрдә авыр кичерешләрне, әйтеп бетергесез бәхетсезлекләрне күп күрергә туры килде.

Инде яңадан 1941-42 нче елларга әйләнеп карыйк. Авыллардан кайтып, яңа программа хәзерләдек тә Калинин фронты ягына юл тоттык. Программабыз ике телдә хәзерләнде. Составыбыз үсте. Ансамбльгә опера һәм балет театры солистлары Асия Измайлова, Андрей Пустоветов, Рус Зур драма театрыннан Евгения Лисецкая кушылдылар.

Зәһәр салкын кышның иң суык көнендә вокзалга җыелдык. Өс киемнәребез бу күрелмәгән салкыннан сакларлык түгел. Аякларыбызда резин итекләр. Безне озатырга килгән художество җитәкчебез Зөләйха Саттаровна Ахметова Совет Армиясе, Совет һава һәм диңгез Флотына сәнгать эшлеклеләренең шефлык итү комиссиясе председателе Б. Л. Военштейнга әйтә: «Мин балаларымны (ул безне «балаларым» дип йөртә иде) бу салкында мондый аяк киемнәре белән җибәрмим. Алар юлда ук катып үләчәк»,— ди. Б. Л. Военштейн каядыр китте, байтак вакыт күздән югалып торды... Без, Кукмара киез итекләре киеп, вагоныбызга кереп утырдык. Вагон уртасында тимер мич. Як-якта ике катлы сәндерәләр... Өстебездәге киемнәрне, киез итекләрне салмыйча йокларга яттык. Иртән уяндым, ә урынымнан кузгала алмыйм. Нәрсә булган? Аңламыйм. Аркамны стенага терәп ятканмын да пальто тән җылысы белән вагон стенасына ябышып, бозланып каткан икән. Иптәшләр мине тарткалый торгач, шатор-шотыр итеп пальто стенадан куба башлады. Авырмын инде, дип борчылсам да, берни булмады. Яшьлек, күңел күтәренкелеге җиңде. Бу хәлне көлешеп уздырдык.

Концертны Татарстанның халык артисткасы Асия Измайлова башлый. Җәүдәт Фәйзи җырларын, рус халык көйләрен җырлый. «Кое буенда» җырын аерата оста башкара. Аннан Евгения Лисецкая шигырьләр укый. Ачык, матур тенор тавышлы Андрей Пустоветов концертны тагы да күтәрә. Ул башкарган күңелле җырлар тыңлаучыларны канатландыра. Бигюләрдән соң, без җырлыйбыз. «Будет Гитлеру конец»,

«Катюша», «Комсомольская прощальная»... Татар халык көе «Минем дустым армиядә»не без Фәвия Хәсәнова белән кара-каршы җырлыйбыз, ә хор кабатлап бара.

Фәвия Хәсәнова җырлый:
Минем дустым армиядә,
Ул җиңеп илгә кайтыр.
Хәзер күңелем боек чагы,
Ул кайткач чәчәк атыр.
Мин дәвам итәм:
Батыр егет кайтуына
Ал кулъяулык чигәрмен.
Батыр егет сугышчыга
Миннән бүләк, диярмен.

Концертлар уңышлы үтсәләр дә, рәхмәт сүзләрен күп ишетсәк тә, Мактау грамоталары алсак та, күңел әрни. Чөнки сугышчылар үлем арасында йөриләр, яуга керәләр. Шуларны күрү авыр иде. Маршрутыбыз Калинин фронты булып, без Калинин, Ярославль, Иваново шәһәрләренә кайткалый идек.

1942 нче Яңа елны Кострома шәһәрендә каршы алдык. Концертлар төрле частьларда — әле танкистлар, әле летчиклар өчен була. Кайсылары хәрби заданиене үтәп кайтканнар да концертка килгәннәр, ә кайсылары концертны тыңлап та бетерә алмыйлар — яуга керәләр. Ә ул китеп баручыларны күңелдән иң матур теләк теләп озатасың. Шул ук вакытта алар өчен борчылу да туа.

Февральдә барыбыз да Казанга исән-сау кайтып кердек. Шунда ук Кукмарага барып, 20 ләп концерт куйдык. Александр Бендецкий концертларыбызны бик оста алып барды. Сугышка кадәр үк татар халык җырларын рус теленә тәрҗемә итә башлаган, ансамбль белән 1940 нчы елда Ерак Көнчыгышта гастрольдә булган яшь язучы Бендецкий безне очрашу безне бик сөендерде. Тәрбияле, тәскә, буйга чибәр, музыканы, поэзияне бөтен барлыгы белән яраткан Александр Бендецкий коллективта зур хөрмәт казанган якты шәхес иде. Кукмара госпитальләреннән соң ул бездән аерылды. Аннан без аның сугыш кырында һәлак булуын ишеттек.

Тагын авылларда гастрольгә чыгабыз. Тагын госпитальләргә кайтабыз. Дүрт ел буе шулай.

Җиңү көне. Филармония сугыш елларында Куйбышев урамында 22 нче йортта, хәзерге Сәүдә работникларының Культура сарае бинасында эшләде. 9 нчы Май иртән филармониягә җыелдык. Ике йөк машинасы безне көтеп тора иде инде. Аларның ян такталары төшерелгән. Барыбыз да машиналарга урнаштык. Алар әкрен генә Бауман урамына таба юнәлделәр, урам уртасында туктап, ике машинаны янәшә куеп, концерт бирәбез: җырлыйбыз, биибез. Халык арасыннан, сикереп менеп, безнең биюләргә кушылып китүчеләр дә бар.

Машиналарыбыз бер урыннан икенче урынга акрын гына күчәләр. Тагын туктыйбыз. Яңадан программабызны кабатлыйбыз. Ә халык шул кадәр күп, алма төшәр урын юк. Җырлар, биюләр һаман агыла. Кичкә кадәр шулай халык шатлыгы диңгезендә йөздек...

Разия ТИМЕРХАНОВА,
Татарстанның атказанган артисткасы.

Ничек яшисең, солдат анасы?

Тынычлык дип тибә һәр йөрәк

«Мин журналның 1984 елдагы август санында «Тынычлык дип тибә һәр йөрәк» дигән мәкаләне укыдым, аннары аны сугышта ирен югалтып, биш бала тәрбияләп үстергән Фатыйма апа Зиннуровага да укып күрсәттем. Аның белән сугыш елларында күргән авырлыкларны сөйләшеп, балаларыбызның ул газапларны күрмәүләрен теләдек».

Лениногорск районының Карагай авылыннан **Рәхимә ЯКУПОВА** редакциягә хатын шул сүзләр белән башлаган. Ул үзе дә фронт юлларын үткән кеше. Өч туган абыйсы, бер сеңлесе дүрт кеше сугышта катнашканнар. Бер абыйсын сугыш кырында югалткан. Ире Лотфрахман белән бергә алты бала үстергәннәр. «Балаларыбыз сугыш күрмәсеннәр иде. Күгебез аяз, халкыбызны туендырган җиребез тыныч булсын иде. Барлык аналар исеменнән язам»,— дип тәмамлый Рәхимә Бәдретдиновна үзенең хатын.

Ирбит шәһәреннән **БАҺАВЕТДИНОВА Вахидә** Башкортстанда Ю. Карыш авылында яшәүче әнисе Саймә белән апасы Нәсимә Фәрхетдиноваларлар хакында яза. «Әтиебез фронтта һәлак булгач, без биш бала калдык. Иң олы апабызга унбер яшь иде. Тормышның бөтен авырлыгы әниебез белән шул апа җилкәсенә төште. Сугыш вакытындагы һәм сугыштан соңгы авырлыкларны өлкәннәр үзләре кичереп, яшьләр исә алардан ишетеп беләләр. Ачлыкны да, ялангачлыкны да татыдык. Безне туйдырыр өчен әниебез көне-төне эшләде. Нәсимә апабыз урман кисәргә йөрде, дуңгыз, сарык, тавык карады, тракторда эшләде, сыер сауды... Ул елларда күргәннәрне язып бетерерлек кенә түгел»,— ди ул.

«Минем Фатыйма һәм Хәдичә апамнар,— дип яза Уфадан **Лена МОРТАЗИНА**,— Җиңү көнен якынайту өчен бер караңгыдан икенче караңгыгача эшләгән кешеләр. Хәдичә апам, өч бала белән калып, җизни сугыштан кайтканчы аларны да әрәмшәрәм итмәде, ирләр белән янәшә печән чапты, урак урды. Бөгелмә станциясеннән чана тартып, орлык ташыды, кичләрен фронтка оекбашлар бәйләде. Аның «арыдым» дигән сүзен бервакытта да ишетмәдек.

Аннары яраларыннан ире үлеп китте, авырлыклар белән үстергән улы фаҗигале төстә һәлак булды.

Апам бирешмәде. Ул һаман да саф күңелле, кешелекле, элеккечә уңган, йорт-җир карап, балаларына ярдәм итеп, оныкларын үстереп яши.

Фатыйма апам да егерме җиде яшендә тол калып (ире сугышта һәлак булды), ике бала үстергән, көне-төне колхозда эшләгән хатын.

Минем апаларым кебек, ирләренең намусына тап төшермичә тормыш иткән апалар бик күп безнең илдә».

Уральск шәһәреннән 72 яшьлек **Гайшә апа УРАКЧЕЕВА**: «Яшьлегемдә күп эшләдем. Комсомолдан башлап төрле эшләрдә булдым. 14 ел авыл Советы председателе булып тордым. 42 елдан бирле партиябезнең кадерле члены булам,— дип хәбәр итә. Ирем Касыйм Уракчеев сугыштан кайтмады. Өч малай, ике кыз тәрбияләп үстердем, барысын да укыттым. Ике кызым — мөгаллимә, өч малаем — зур инженерлар. Яхшы эшләп, семьялары белән матур тормышта яшиләр».

Солдат хатыннары тормышына игътибар итеп язылган мондый хатлар редакция почтасында сирәк түгел. Төрле яклардан, төрле яшьтәге кешеләрдән килсәләр дә, ул хатларны асылда бер зур хис берләштерә: сугыш елларын кичергән, сугышта явыз дошманны, өскә килгән үлемне җиңгән буынның фидакарьлеген тану, аларның газаплары һәм батырлыгы алдында баш ию.

Тагын хатларда илгә Җиңү яулаган, илнең балаларын саклап калган, илне сугыш җимерекләреннән күтәргән буын хатын-кызлары — бүгенге карт аналар, әбиләр турында кайгырту бар. Сугыш ветераннарына бездә хөрмәт, ярдәм, льготалар зур. Тик, шушы матур гадәтләребезне үтәгәндә, без кемнәрнедер үпкәләтмибезме? Әйтик, әбиләр чиратта, ә бабайлар, алар алдына керреп, үзләренә кирәкне алып китә тора. Яки сугыш елларында барлык авырлыкларны күтәрешкән әбиләрне кадер-хөрмәттән, игътибардан читтә калдырабыз. «Хәзер без бай, бер әйбер дә кирәкми, тик җылы сүз генә кирәк, күңел түренә җылы сүз»,— дип зарланган Туймазыдан **Г. ЗАКИРОВА**. «Тиздән Җиңү бәйрәменең 40 еллыгы. Әни шикелле, апам шикелле тылда тырышкан кешеләрне дә онытмасыннар иде»,— дип үтенә **Вахидә БАҺАВЕТДИНОВА**.

Бүгенге көндә Андижан шәһәрендә яшәүче **Галия КИЛЬДИШЕВА** үзенең туган-үскән Саратов өлкәсе Сафарка авылы кешеләрен, сугыш елларында батырлык күрсәтеп эшләгән, яшәгән авылдаш хатын-кызларын искә ала. «Ирләре сугыш батырлары булса, үзләре авылда эш батырлары булдылар»,— ди ул. Аларның авылында картларга, солдаткаларга игътибар зур икән. Галия апа моның өчен колхоз авыл Советы җитәкчеләренә авылдашларының рәхмәтен җиткерә, яшьләрне әтиләренең, әниләренең яхшылыкларына лаеклы булырга өнди. «Ничек яшисең, солдат анасы?» дигән мәкаләгезне укып, күңелем тулды,— дип мөрәҗәгать итә ул редакциягә.— Солдат аналарының, солдат хатыннарының хәлләрен сорап язгансыз. Бу бит аларга нисбәттән хөрмәт. Алар өчен зур шатлык. Чөнки солдаткалар, солдат аналары, сугыш алдыннан туып калган балалар — сезнең, безнең өчен сугышып, сугыш кырларында ятып калган туганнарыбызның семьялары.»

Галия апа үзенең хатын:
«Җир йөзендә тынычлык булсын, Сугыш булмасын, дип Теләк тели барча аналар»,— дип тәмамлый.

Аналарның да, балаларның — барыбызның да иң изге теләге бу.



Совет хатын-кызлары комитеты членнарыннан бер төркем. *Н. Белецкий фотосы.*

СОВЕТ ХАТЫН-КЫЗЛАРЫ КОМИТЕТЫНДА

Январь ахырында Совет хатын-кызлары комитетының чираттагы Пленумы булып үтте. Пленумда комитет председателе иптәш В. В. Терешкова «Германия фашизмын һәм япон милитаризмын Җиңүнең 40 еллыгы уңаеннан Совет хатын-кызлары комитетының бурычлары» дигән доклад сөйләде.

Быел планетабызның бөтен прогрессив кешеләре зур юбилей — Җиңүнең 40 еллыгын бәйрәм итәчәкләр. Алты ел буена Европа, Азия, Африка илләре икенче бөтендөнья сугышы ялкынында җәфа чикте. Кырык илдә кан коелды, яшь түгелде. Җир шарының биштән дүрт өлешен сугыш үзенә тартып алды. Чал тарихның андый авыр сугышны моңа кадәр күргәне юк иде әле. Илле миллион кешенең тормышын кисте ул. Сугышлар тукталгач та әле атом-төш нурланышыннан һәм яралардан 300 мең кеше вафат булды. Чал тарих моңа кадәр гитлер рейхы һәм аның союздашлары уйлап тапкан берсеннән-берсе куркынычрак, вәхширәк планнарны да белмәде: үзләре түбән дип саналган бөтен бер милләтләрне, халыкларны юк итү; иксез-чиксез мәйданнарны үле чүл хәленә китерү — фашистларның планы шундый иде.

Бөтен көчне туплап, бик күп корбаннар бәрабәренә генә цивилизацияне саклап калып булды. Планета өстенә фашизмның кара пәрдәсе ябылмыйча калды.

Совет халкы һәм аның Кораллы Көчләре басып алучыларны тар-мар итүдә хәлиткеч көч булды. Икенче бөтендөнья сугышында һәлак булганнарның яртысы диярлек совет кешеләре — сугышчылар, хатын-кызлар, балалар иде. Безнең халык Атлантикадан алып Тын океанга кадәр сузылган иң авыр, иң күп көч һәм техника тотылган сугышларда җиңеп чыкты.

Безнең Фронт — үзәк фронт булды, монда бөтендөнья сугышының Бөек Җиңүгә таба борылышы билгеләнде. Мәскәү белән Сталинград шәһәрләре тарихта Бөек Җиңүнең бишеге булып саналачак.

Совет халкы героик көрәштә Ватаныбызның азатлыгын һәм бәйсезлеген саклап калды, алай гына да түгел, көнчыгыштагы һәм көнбатыштагы бик күп илләрне фашистлар коллыгыннан коткарды.

Фашизм, алар башлаган сугыш — зур фаҗига булды. Бу фаҗигадан халыклар уртак дошманга каршы тору һәм бердәмлек тәҗрибәсе алдылар.

Азатлык армияләре, Каршылык хәрәкәте геройлары, фашистларга каршы яшерен сугыш солдатлары фашизм коллыгындагы бөтен халыкларның көчен, тырышлыгын берләштерү нәтиҗәсендә генә уңышка ирештеләр.

Җиңүнең 40 еллыгын бәйрәм итүгә әзерләнгәндә, без немец фашистларының һәм япон милитаристларының үз халыкларын да канлы упкынга ташлаганнарын искә алабыз. Хәзер Җирдә яки галәм киңлекләрендә сугыш башларга әзерләнгән илләр бу турыда ачык белергә тиешләр, сугыш афәте аларның үз илләрен дә себереп түгәчәк.

Совет кешеләре сугыш авырлыгын үз җилкәләрендә күтәрделәр, кара кайгысын йөрәкләреннән үткәрделәр. Ирләр дә, хатыннар да. Әйе, без — хатын-кызлар — әтиләребез, ирләребез, туганнарыбыз язмышын тулысынча уртаклаштык. Без солдатлар да булдык, сукага да җигелдек. Без — хатын-кызлар — атакалардан ташландык һәм җимерелгән шәһәрләрне яңадан торгызыдык. Без үтерелгән полкташыбызның кабере өстендә дә еламаска һәм «похоронка»лар алгач та күз яшебезне ятимнәргә күрсәтмәскә өйрәндек.

Без гади бер хакыйкатьне беләбез: сугышка каршы көрәшне туплар шартлаганчы ук башларга кирәк. Бу — дәвамлы көрәш, кыюлык һәм батырлык сорый торган көрәш. Җир шарының бүгенгесе һәм киләчәк буыннары өчен җаваплы булган һәр кеше тынычлык өчен көрәшкә кушылырга тиеш.

Империализм һәм агрессия көчләре бүген яңадан коточарлык планнар коралар: демократия һәм социализмга каршы «тәре походы» да, дөньякүләм өстенлек тә, нацизмны яңадан торгызу да — аларның хыялында. Тынычлык яклаучыларның бурычы бер генә — сугышны булдырмау, атом сугышыннан планетаны саклап калу.

Шушы лозунг астында сугышка каршы бөтендөнья хәрәкәтендә төрле илләрнең хатын-кызлары алгы сафларда баралар.

Совет хатын-кызлары комитеты Пленумында чыгыш ясаучылар менә шулар турында фикер алыштылар. Бөек Җиңүне нинди хезмәт бүләкләре белән каршылауларын, Тынычлык фондына күпме акча күчерүләрен, яшь буынны интернациональ һәм патриотик рухта тәрбияләүләрен сөйләделәр.

Пленумда катнашучылар «Халыкларның тормышка хокуклары» дигән Белдерү һәм Бөтендөнья Демократик хатын-кызлар Федерациясенең 40 еллыгы уңаеннан Котлау кабул иттеләр.

«Фашизм кабатлануына юл куймыйк!»

«Тынычлык өчен көрәштә көчләребезне берләштерик!»

«Планетабыз өстенә ябырылган атом-төш сугышы куркынычын бергәләп юк итик!»

«Халыкларның иң беренче хокукын — яшәү хокукын саклап калыйк!»

Пленум бөтен дөньядагы хатын-кызларга әнә шулай мөрәҗәгать итте.



Р. ЯКУПОВ фотосы.

БӘБИЛӘР

Бәбиләр туды. Дөньяга берьюлы өч бәби, өч Кеше аваз салды. Берьюлы өчәү! Бер әнидән. Малайның авырлыгы 2 кило да 200 грамм, кызларның берсе — 1 кило да 200 грамм, ә икенчесе — 1 кило иде. Малайга — Радик, кызларга — Рания, Раилә дип исем куштылар. Биш яшьлек Рәмилә белән дүрт яшьлек Румиянең, шулай итеп, берьюлы 2 сеңелесе һәм энесе булды. Ә әни кеше Рәшидә Кәримовага әле 26 гына яшь тулган.

Рәшидә үзе дә ишле гаиләдә үскән. Әнисе Саймә апа (Герой-ана!) белән әтисе Кадыйр абый 10 бала үстергәннәр. Ә әбисенең сеңелесе үз заманында игезәкләр дә тапкан булган. Кайнанасы Шәмсенур апа да 8 бала үстергән.

— Рәхмәт хөкүмәтебезгә! Рәхмәт врачларга,— ди Шәмсенур апа бу өч оныгы турындагы сүзгә кушылып. — Тугач та Казан больницасына алып киткәннәр иде, ике ай эчендә «үсеп» кайттылар.

— Дөньялар гына тыныч булсын! — дип өсти аннары әни-кайнана. — Илебез бай, илдә булгач, өйдә муллык, тәгәрәшеп үсәрләр, боерган булса. Рәшидә киленгә булышырга пенсионер картлар — менә без дә бар, — ди ул карты Маликка ишарәләп...

Бәбиләрне рәсемгә без үз өйләрендә (Апас районының Кормаш авылы) 5 айлык вакытларында төшереп алдык. Ә бүген аларга — 8 ай.

Бәхетле әни — Рәшидә «Ракета» колхозының алдынгы терлек-караучысы, ә бәхетле әти — Рәүхәт алдынгы механизатор.


Казан авиация институты студенты Әлфия Фарукшина.


РӘХМӘТ КУЛЛАРЫГЫЗГА!

КамАЗдагы пресс-рам заводында. Штамплаучы Исламия Ибраһимова.




Чистай сәгать заводы контролеры Антонина Данилова.


Студентлар җәйге практикада.



Хатын-кызлар катлаулы техника белән идарә итәләр.




Әниләрнең, апаларның, сеңелләрнең куллары хакында сүзне «йомшак, җылы, назлы» дип башлыйсы килә. Безнең башларыбыздан сыйпаганда, безгә беренче адымнарыбызны атларга ярдәм иткәндә, тәмле ризыклар пешергәндә нәкъ шундый алар. Үзләренең йомшак, җылы назы белән алар безнең өйләргә һәм күңелләргә нур иңдерәләр.

Ләкин ул куллар турында болай гына дип әйтү аз, бик аз шул әле. Колхоз һәм совхоз кырларында, терлекчелек комплексларында һәм фермаларда, фабрикаларда һәм завод цехларында, мәктәпләрдә, больницаларда һәм поликлиникаларда, фәнни лабораторияләрдә безнең хатын-кызларыбызның куллары тагын бик күп күркәм сыйфатларга ия булуларын исбат итәләр. Хезмәттә һәм иҗатта алар өлгер, җитез, төгәл, нык, көчле, арулталуны белмәс осталар. Ил тормышында алар керткән өлешне бәяләп бетергесез. Шәхси тормышта аларсыз яшәү мөмкин түгел.

Бу рәсемнәрдә сез төрле һөнәр ияләрен күрәсез. Кызганычка каршы, без барлык һөнәр ияләрен дә күрсәтә алмыйбыз, чөнки хатын-кызлар башкара торган хезмәт һәм иҗат төрләре санап бетергесез.

Бүгенге бәйрәм көнендә барлык хатын-кызларыбызга, чын халыкча итеп, матур теләк телисе килә:

Рәхмәт кулларыгызга!
Алсу гөлләр чәчәк атсын
Йөргән юлларыгызда!



Казандагы 10 нчы интернат-мәктәптә дәрес бара.

Р. Якупов, Э. Хәкимов, Р. Мөхәммәтҗанов, Ю. Филимонов һәм Н. Коцага фотолары.



Сөт заводы лабораториясендә.



Җиргә нык-нык басып, урам уртасыннан яланаяклы, озын чыбыклы Филзия бара. Сыерлары көтүдән кайтмый Филзияләрнең, гел авыл башындагы бодайга чаба. «Имансыз сыер!» — ди әбисе, Филзия дә шулай кабатлый. Имансыз булса да, матур сыер ул, бөдрә койрыклы, тик бер җилене кыек, интегәм, ди әбисе.

Әбисе сыер артыннан йөри алмый, карт инде ул, аяклары да авырта, күзе дә начар күрә. Малларны гел Филзия алып кайта, ул күршеләрнең дә малларын таный. Менә Мәдинә апаларның сыеры Филзияләрнекенә охшаган,

З. МӨХӘММӘТҖАНОВА рәсеме.

Филзия

Нурия ИЗМАЙЛОВА

ХИКӘЯ

аның апасы ул, Мәдинә апалардан алдылар Филзияләр бу сыерны.

Авыл башына җитәрәк, Филзия кечкенә коляска тартып уйнап йөргүче өч яшьлек Айсылуны күрә.

— Айсылу, безнең сыерны күрмәдеңме?— дип сорый.

— Нәмәкәйне?— ди Айсылу кашын җыерып.

— Сыерны.

— Кемнәлнекен?

— Безнекен.

— Күлдем, күлдем, а-а-а-на тегендә, өскә менеп кителәл. Җиләккә киттеләл, җиләк ашыйлал да кайталал...— ди Айсылу.

Сыерлар чынлап та Айсылу күрсәткән якта иде, анысын болай да белә иде Филзия, тик алар җиләккә бармыйлар шул, бодайга баралар. Айсылу бәләкәй, аңламый, ә Филзиягә инде алты тулды. Быел әнисе алып китә аны, ә киләсе елга ул укырга керә.

Филзия үзләренең сыерын бөдрә койрыгыннан танып алды да бик ачуланып әйтте:

— Ах, имансыз! Тагын шушында килдеңме!? Туймас тамаккаең булды инде...— Маллар белән әбисе шикелле сөйләшә ул, бүтәнчә сөйләшкәнне аңламый бит алар. Ул, чыбыгын болгап, батыр гына бодай арасына кереп китте. Ах, шайтан, аякка әллә нәрсәләр кадала, башаклар шап та шоп тезгә бәрәләр. Сыер янына килеп җитүгә, тегесе, Филзияне танып, икенче башка чаба. Филзия аны куркытып-куркытып тирги:

— Әле качасыңмы! Ну, белеп кенә тор, белеп кенә тор. Без сине...

Ә сыер курыкмый. Зур авызын әйләндереп-әйләндереп чәйнәвен белә. Филзия килеп җитсә, тагын бүтән урынга күчә... Филзия, йөгереп килеп, аңа чыбык белән сукмакчы булды, тик, аягына бодай сабаклары уралып, капланып егылды. Сикереп кенә торды да җан ачуы белән сыерга сыптырды! Тегесе торып чапты. Филзия аның артыннан! Чабыша торгач, чөгендер басуына килеп чыктылар. Уф! Филзиянең бер тамчы да хәле калмады. Тик сыерны алып кайтырга кирәк. Саумый калдырсаң, сөте бетә бит аның. Ә иртәгә сепарат аертасы бар. Озакламый Филзиянең әнисе кайтырга тиеш, күп кенә май язып куярга кирәк, озак кына торсын әнисе! Ә-әй, онытып та җибәргән, Филзияне алып китәргә кайта бит әле ул! Юк, тизрәк китсен, Филзияне дә алып китсен. Әнисе Мәскәүгә алып китә бит аны, ә Мәскәүдә мороҗный бар, әфлисун да бар, әнисе аңа көн саен бер әфлисун алып бирер, ә юк, икене, иртән берне, кич берне.

Әй, бу сыерны барыбер алып кайта ул! Филзия тагын йөгерә. Басуның теге башында атка атланган басу каравылчысы күренә. Ә-ә, бик әйбәт, хәзер куып чыгара ул бу сыерларны!

— Нигә сыерыңнан басу таптатасың?— дип кычкыра Нурислам абзый, ат өстендә чыбыркысын болгап.

— Ул таптамый. Ашыйсы килгән аның,— ди Филзия, сыерны яклап.

— Ашатырмын әле менә мин сезне!— дип ачулана Нурислам абзый, Чыбыркысын селтәп, сыерга сукмакчы була. Суктырды ди сиңа! Таный ич аны сыер, шундук басудан кача! Ару булды. Хәзер йөгертеп кенә алып кайтабыз аны. Нурислам абзый кычкырып кала:

— Чыгарасы булмагыз сыерыгызны!— ди.

Әйтерсең, чыгарган кеше бар! Үзе китә бит ул. «Көтүдә бернәрсә юк малларга ашарга»,— ди ич әбисе. Сыер гаепле түгел инде. Ярый әле, суга алмады Нурислам абзасы...

Көчкә алып кайтып җиткерде Филзия сыерны. Кып-кызыл булып пешкән иде капка төбенә җиткәндә, сыдырылган аяклар да ут булып яна. Шулай да хуҗаларча канәгать чырай белән кертте сыерны.

— Әби-и! Сау сыерыңны! Апкайттым!— дип кычкырды.

Бәй, бу ни эш! Утарга инде икенче сыер ябылган... Мәдинә апаларның сыеры бит бу!

— Әби!..

Бабасы алып кайтып биргән икән бу сыерны. Әбисе танымыйча сауган.

— Их, әби! Бабай начар күрә бит ул, син аның сүзенә ышанып торасыңмы!— диде Филзия, әбисен битәрләп.— Бу сыерның бит койрыгы бөдрә түгел, күрмәдеңмени!

— Күрмәдем шул, балам, караңгы бит, күзләрем начар бит...— диде әбисе бик оялып. Әбисенә кыен булгач, Филзиягә дә кыен булып китте: «Кыек җиленнән булса да танырга не!»— дип әйтмәде...

Үз сыерларын да саудылар, Мәдинә апаларның сыерын да, сөтен дә илтеп бирделәр. Филзия җылы сөт эчте дә әбисе янына менеп ятты. Әбисе аны кочаклап сөйде дә мактады:

— Ярый син бар әле, балакаем. Кем булышырые әбиеңә!— диде.

— Мин китсәм, нишләрсең инде, әби!— диде Филзия, авыр сулап.

— Белмим инде, бәбекәем, белмим...

— Әби, сине дә Мәскәүгә алып китимме? Калсын бабай сыер белән. Без китсәк, үзе дөньҗа көтәр әле!

— Әй, балам...— диде әбисе.— Йокла инде, йокла.

Филзия йокларга яткач, гел әнисен уйлый, төшкә керә ул уйласаң. Аның әнисе шундый матур! Төшкә керсә, бик рәхәт була! Ә менә әтисе бер дә төшенә кергәне юк, чөнки Филзия белми аны. Ул еракта, укый да укый, диләр һаман. Җәй көне нигә каникулга кайтмый икән? Укучыларның бит каникулы була. Кайтмаса! Филзия аны сагынмый да. Төшкә кермәгәч, сагынмыйсың инде. Ә менә әнисен ул бик сагына, гел «кайтсын» дип теләп йөри. Быел алып китә инде! Тик әбисе: «Быел гына алып китәлмас шул әле»,— ди. Алып китсе-е-н! Филзия әбисен яратса да, әнисе белән торырга тели шул. Аның эшләгән җирен күрәсе килә: җылы микән эшләгән җире, өшемиме икән? Баргач та мич ягып җибәрәме икән? Әнисенең маллары булса, аларны да таныр иде Филзия, алып кайтыр иде. Әбисе әйтә: «Бигрәк мал җанлы минем кызым»,— ди. Әбисе әйбәт шул. Ә әнисе бигрәк чибәр, аның белән урамнан җитәкләшеп үтүе күңелле. Тик әнисе кайчагында Филзияне кочаклап елый. Филзиягә барыбер рәхәт була. Ә бер тапкыр, Филзия өйдә юк дип белеп (ул өйалдында иде), әнисе әбисен ачуланды:

— Шул баланың өстен генә чиста тоту кыен түгел бит инде,— диде.— Карале чәчләрен, аякларын, кулларын... Ташландык бала кебек!

Әбисе елады:

— Алты айдан кайтарып ташладың. Алты яшькә җиткердем. Ничек телең бара битәрләргә!— ди.— Башыннан чәчен дә төшертмичә өф итеп кенә торам. Ятим үсә, дип көн-төн яшь түгәм... Атасы бар, дип авыл буйлап хәбәр тарата...— ди.

Аннан икәүләп еладылар. Аларга күренмичә генә Филзия дә елады, әллә нигә елыйсы килде дә...

Әнисе киткәч, бер тапкыр әбисеннән сорады Филзия:

— Әби, ятим ничек була?

— Әнисе булмаган кеше була,— диде әбисе.

— Ә әтисе булмаган кеше нигә ятим булмый?

— Зур кызлар гел нигә дип төпченмиләр,— диде әбисе.

Бәләкәйләргә генә ярыйдыр инде төпченергә, нигә дә нигә дип...

Ә Филзия зур кыз. Киләсе елга укырга керер. Мәскәүдә. Авылга җәй көне каникулга кайтыр. Әбисенә булышып китәр. Ә әбисе Мәскәүгә китми инде ул сыерны ташлап.

Филзиянең зәңгәр күзләре йомыла бара, йомыла бара... Әкренләп төшләр керә бара... Гел сыер да сыер... Әнисе һаман юк та юк...

Рэйсә ИШМОРАТОВА

ХИКӘЯ

Байтак көннәр инде диңгез буенда ял итәбез. Төрле тарафтан, төрле авыл һәм калалардан килгән кешеләр, гомере буе бергә көн иткәннәр дияргсең, дуслашып, туганлашып беттек.

Ялга килүемнең беренче көннәрендә үк мин алты яшьлек Фуат белән дуслаштым. Хәер, мин генә түгел, безнең санаторийда ял итүче бик күпләр бу сөйкемле малайны үз итте.

Иртәләрен яр буена физзарядкага җыелабыз. Бездән ерак түгел генә җирдә озын буйлы, утыз яшьләр тирәсендәге нык бәдәнле бер ир үзе ясаган күнегүләргә кечкенә Фуатны да өйрәтә. Бу ир кеше — Фуатның әтисе. Улын зур сабырлык белән йөзәргә өйрәтүен дә кызыксынып күзәтәбез. Малай көннән-көн остара, кыюлана бара. Шактый арага йөзеп керә. Чумгач, бик тиз су өстенә калыкса да, әтисеннән:

— Су астында мин ничә сәгать булдым? — дип сорый. Аңа секундлар, минутлар гына бик аз, водолазларча сәгатьләп кирәк!

Фуатлар безнең корпуста яшиләр. Еш очрашабыз. Һәр очрашкан саен, малай миңа берәр яңалык сөйләми калмый. Я диңгез теплоходында сәяхәт кылган булалар алар, я әтисе яңа китап алып кайткан да бергәләп укыганнар, яисә икәүләп базарга барып килгәннәр, кибетләрдә йөргәннәр...

Ә Фуатның иң куанычлы сәгатьләре өйләреннән, әнисеннән хат килгән көнне була. Андый чакларда аның иреннәреннән елмаю китми, ул бер урында тик кенә басып тора алмый башлый, куе керфекләр каймалаган соры күзләре зур булып ачыла да, аларда бәхет очкыннары биешә башлый. Сабыйларга хас беркатлылык белән ул, өтерсез-ноктасыз дигәндәй, кызу-кызу сөйләп китә:


— Бүген әниемнән хат килде! Күп итеп язган, ике бит... Миңа дигәне — бер бит. Мин әле кечкенә иң. Әнием безне аэропортта каршы алам, дигән. Минем кечкенә сеңелем бар, Ләйлә. Аны да аэропортка алып килэм, дигән... Беләсеңме, минем әнием бик матур ул.— Шулай дигәндә, аның тавышы пышылдауга күчә, гүя ул бу серне миңа гына ышанып сөйли.— Безнең әни бик матур да, әйбәт тә. Әйеме, әтием?— Ул, күзләрен мөлдерәтеп, әтисенә карый.

— Дөрес, улым! — дип рухландыра аны әтисе.

Әнә әле хәзер дә алдына бер өем ташлар җыйган да шулар хакында әтисе белән әңгәмә кора. Әти кеше диңгезнең бу ташларны ничек шомартканын сөйли.

Әтисе аның бер соравын да җавапсыз калдырмый, сораганын эшли тора. Кыскасы, улына бик илтифатлы, ләкин таләпчән, кирәге чыкса кырыс та була белгән бу атага бездә ихтирам туып өлгергән иде.

Баксана, әти кеше, уң кулы белән диңгез эченә ишарәләп, нәрсәдер сөйли. Фуатның йөзе җитди. Әтисе бер кыска гына таяк ала да, кизәнеп, аны җиргә кадый. Аннан таякны





Берәр кызыклы шигырьгә тап булсаң, аны якыннарыңа да укып күрсәтәсе килә. Сиңа ошаган шигырь башкаларның да күңеленә хуш килсә, аның авторын тагы да киңрәк аудиториягә тәкъдим итү теләге уяна.

Менә мин дә үсисгез яшьлек шагыйрә Алсу Гайнуллинаны сезнең белән таныштырмакчы булам, хөрмәтле әдәбият сөючеләр. Ул Арча педагогия училищесында укый. Туып-үскән төбәге — Балтач.

Шигырьләрнең бай характерлы булуы, самими ихласлылыкны һәм, әйтергә кирәк, тирән фикерләрне сыйдырышлы метафоралардан торуы, заманча кискен ритмикага корылуы мине аерата җәлеп итә.

Ренат ХАРИС.

Алсу ГАЙНУЛЛИНА

Диңгезчемә

Ара —
Безнең өчен яра.
Синең өчен
диңгез дәва,
Минем өчен
дәва юк.
Синдә — диңгез,
Миндә — ут.
Миңа сине бирмәс өчен
Диңгез чайкый дулкын-көчен.
Онытмаска теләп мине,
Яр буена кабат килдең,
Һәм хыялым булып минем,
Җилкәй сиңа: «Саумы!» — диде.
Ара —
Безнең өчен яра,
Якынайтмый аны диңгез.
Син диңгездә.
Ә мин — синсез.
Онытмыйча яшәп кара!

Бер күрмәсәм — бер күрермен,
Өзәрмен үзгәнне,
Белсәм дә ярата торып
Килмичә түзгәнеңне.
Бер елмайсам — бер елармын,
Гафу итмичә сине.
Үч алмам мин, көч алырмын
Үз итүеңнән мине.
Бер килмәсәң — бер килерсең,
Тик ул чакта мин булмам.
Ә хәзергә күбәләк күк
Мин керфегеңә кунам.
Һәм карашыңнан туңам,
Карлы-бозлы җыр булам...

Еллар үткәнен сизмичә,
Биеклеккә омтылганда
Сулыш алу рәхәт икән —
Борчуларга бирелмичә.
Ә яшьлекне сагынганда
Күздән яшьләр тама микән
Кешеләргә күренмичә?
Әллә инде истәлекләр
Яра булып күңелләрдә
Мәңгелеккә кала микән?

ДИҢГЕЗ БУЕНДА

суырып алып, улына бирә. Фуат, әтисе шикелле итеп, бөтен көче белән таякны җиргә батыра. Шуннан соң икесе дә кычкырып көләләр. Малай йөгереп суга кереп китә, әти кеше аның артыннан:

— Пычагыңны алмадың бит, улым! — дип кычкыра һәм, әлеге таяк кисәген тотып, улы артыннан диңгезгә керә.

— Пычак? — Мин һәм янәшәмдә кызынып утыручылар, гаҗәпләнә калып, малай белән әтисенә карыйбыз.

«Пычак» дигәннәре әлеге дә баягы шул таяк икән. Без җиңел сулап куябыз.

Бераздан малай ярга чыгып ятты.

— Булды! — диде ул. — Акуланы чәнчеп үтердем. Әтигә дә, мица да тия алмады... — Аның кыяфәте галәмәт горур иде.

— Улын батырлыкка өйрәтә, молодец! — диде арабыздан берәвебез.

— Батырлык пычак кадап, кан агызу түгел! — диде икенче берәү.

— Баланы шәфкатьсезлеккә өйрәтүне хупларга ярамый... — Тагын кемдер шулай дип өстәде.

— Шәфкатьсезлеккә түгел, кыюлыкка өйрәтә ул аны...

— Шулай итеп, безнең төркемдә шәфкатьсезлек һәм батырлык-кыюлык хакында фикер каршылыгы калкып чыкты.

Көннәр уза торды. Без инде ял итүдән ялыга башлаган идек. Кайтыр көннәребезне ешрак искә ала башладык. Ата белән малай да ял итеп туйдылар булса кирәк, кояш белән бергә торып, коенырга йөрми башладылар. Кайчакларда әти кеше ялгызы гына коенып китә иде.

— Әллә Фуат авырып киттеме икән?

— Су коенырга бик ярата иде бит!

— Кичә төнлә мин стена аша Фуатның җылаганын ишеттем. Әтисе аны ялгызын гына бикләп калдырган бугай...

Имеш-мимешләребезгә җавап табылды. Кичке аш алдыннан төркемебез белән коенырга дип су буена килдек.

— Әнә алар, — диде Фуатны минем кебек үк үз итәргә өлгергән бер ханым.

Яр буенда Фуат үзе шикелле үк бер малай белән уйнап утыра, алар янындарак кына, сары чәчләрен ал яулык эченә бәйләп, алсу купальник кигән яшь кенә бер ханым белән әтисе, ташлар өстенә чалкан ятып, кояшта кызыналар иде. Озак та үтмәде, Фуатның әтисе белән әлеге ханым, диңгезгә кереп, шаярышып сөйләшә-сөйләшә, йөзә, коена башладылар. Фуат, сул кулын маңгаена куеп, тегеләрнең шактый ерак йөзеп китүләрен карап торды да, башын түбән иеп, теге малай янына килеп утырды...

Кайсыбыз китап укый, кайсыбыз дөньяның мәзәк хәлләрен сөйләгән булып маташа, малайларга игътибар итми башладык. Кинәт, колакны ярып, бер малайның елап җибәргәнен ишеттек. Нәрсә бу? Фуат әле генә үзе белән уйнап утырган малайны җиргә еккан да йодрыклары белән башына төя. Алай гына да канәгать булмагач, баягы таягы белән аның күкрәгенә төрәде.

Шул чак әтисе йөгереп килде дә Фуатның кулыннан таякны тартып алды.

— Нишлисең, малай актыгы?! — Әти кеше гайрәтле җилкенеп, Фуатны читкә тибәрде. Фуат йөзе белән таш өстенә барып төште. Теге малай да урыныннан торды һәм үкси-үкси әнисенә зар түгәргә кереште.

— Әни-и, ул мине акуланы үтергән кебек үтерәм диде...

Әтисе Фуатны елап яткан җиреннән сөйрәп торгызды.

— Торган бул, шыңшуыңнан туктаган бул, әшәке малай! — диде ул аңа сүзләрне теш арасыннан сытып чыгара-чыгара.

Фуат, бар көченә тартылып, әтисенең кулыннан ычкынды да читкә тайпылды. Аннары теге ханымга карап:

— Чәнчим шул! Нигә үрти ул мине?! — диде.

— Нәрсә дип үрти соң ул сине, Фуатик? — Теге ханым малайның башыннан сыйпап сорады.

Фуат яшьле күзләрен кул аркасы белән сөртеп алды да:

— Җибәрмим әтине! Без иртәгә өйгә китәбез. Әни безне аэропортта каршы ала! — дип янә үкси башлады.

— Шул гынамы? — диде ханым, кычкырып көлеп. Ә ир, кинәт нидер хәтерләгән төсле, улына таба атлады.

— Нигә соң син Сережаның башына таяк белән суктың? — дип төпченде ханым. — Әдәпсезлек бит бу, иптәшеңне кыйнарга ярамый, син зур үскән инде...

— Ул әйтә бит, синең әтиең минем әнине ярата, мине дә ярата, ди. Без аны үзебез белән алып китәбез, ди.

Ата белән яшь ханым бер-берсенә карашып куйдылар. Аларның йөзләре кызарган иде. Читтәге кешеләрнең дә Фуат сүзләрен ишеткәнлеген абайлаган ата кеше:

— Җитте, юк сүзләр сөйләмә! — диде. Кырыс итеп, төксе итеп әйтте.

Фуат тагын ярсыды.

— Мин әниемне сагындым. Аэропортта каршы да алмас әле менә. Мин әниемне бик сагындым, — дип такмаклый-такмаклый, елап, корпуска йөгерде.

Әти кеше ни дияргә дә, ни кылырга да аптырап, беравык басып торды. Ул әле генә яшен сугып узган агачны хәтерләтә иде. Янәшәсендәге ханымга нидер әйтмәкче булды, тик әйтмәде, әйтә алмады. Чигәләренә ишелеп төшкән куе чәчләрен артка сыпырды да, тигезле-тигезсез адымнар белән улы артыннан китте.

Коктебель — Казан.

Сездә булган истәлекләр
Хәтер өчен дәвалаумы,
Әллә инде яра микән —
Иң кадерле истәлекләр...
Кире үткәннәргә кайтып,
Элек йөргән эзләреннән
Кеше кабат атлар микән?
Я ул эзләрне югалтып,
Ул шатланмас, киресенчә,
Әллә инде елар микән
Бөтен дөньяны уйлатып,
Истәлекләрне югалтып?..

•

Берүзем теләдем
Ачарга сереңне,
Көннәрне санарга
Түзмәде йөрәгем.
Каршыңа мин киләм,
Арага үч итеп.
Еракка ук китеп
Үземнең өемнән.
...Юлбарыс читлектә
Берүзе тилмергән.
Соңыннан тилергән,
Чыкмагач иреккә...
Йөрәгем читлектә
Ничә ел яшәде, —
Күрмәде рәшәне,
Кояшны — биектә.
Түзмәде соңыннан
Һәм читлек юк булды.
Ә йөрәк омтылды
Җыр тулы юлыңа.
Каршыңа мин киләм,
Елларга үч итеп.
Еракка ук китеп
Үземнең өемнән.

•

Бүлгәләр иделәр
Бу җирне бик күпкә,
Әгәр дә йолдызлар
Янмаса гел күктә.
Төн саен йолдызлар
Кисәтә кешене:
— Онытма беркайчан
Син иң төп эшеңне!
Ә Кеше дигәннең
Йөзләре күп төрле:
Кайсысы — бик чиста,
Кайберсе — бик керле.
Иң начар уйлардан
Йолдызлар ояла,
Һәм йолдыз нурлары
Югала,
югала...
Я, ярыйк җир шарын
Биш-алты кисәккә,
Бу көнгә гасырлар
Аркылы килсәк тә,
Кояштан оялмыйк,
Оялмыйк намустан.
Кем инде үләргә
Шулкадәр ашыккан?!
Булмас бу!
Булмас бу!!!
Җир калыр шар булып,
Ә Кеше йөзләре,
Керләрдән арынып,
Чистарыр
һәм аклар
Йолдызлар фикерен.
Ул көнгә йолдызлар
Барыбер китерер.

•


Сүтелде
Үрелгән толымнар.
Ә үргән чагымда
Мин теләк теләдем:
Бары тик син генә,
син генә,
Дип типте йөрәгем.
Беркемгә чишмәгән серемне
Чәчемә урадым.
Чәчемә — сөйләдем.
Мин үргән толымнар чыннан да ник иде,
Тик алар мәңгегә таралды бит инде!..
...Нигәдер сүтелде
Үрелгән толымнар.
Ник чиштем серемне —
Үкендем соңыннан.


Гашыйк кеше көчлерәк



Ренат ХАРИС
сүзләре

Сара САДЫЙКОВА
музыкасы





Эзләдем дә таптым сине —
Каршыңда басып торам.
Ник эзләдең, дип сорама,
Ничек таптың, дип сора.

Кушымта:

Талпынган чакта йөрәк
Барлык-барлык тылсымчыдан
Гашыйк кеше көчлерәк,
Гашыйк кеше көчлерәк,
Гашыйк кеше көчлерәк!

Киек каз юлларында мин
Адашам диеп торам.
Ник меңдең, диеп сорама.
Ничек кайттың, дип сора.

Кушымта.

Йолдызлардан нур алганда,
Янып үләм дип торам.
Ник алдың, диеп сорама,
Ничек түздең, дип сора.

Кушымта.

Салисә ГӘРӘЕВА

Кызыл җиләк тулы ал учымны
Иренеңә синең китердем:
Җиләкнең дә, яшерен теләкнең дә
Татлы тәмен авыз иттердем.

Син түймадың. Тагын җиләк сондым,
Тәлгәшеннән сөмләп алларын,
Һәм үзем дә кинәт бергәлекнең
Татлылыгын тулы аңладым...

Баш очында кызыл җиләк иде,
Бал кортлары ширбәт эчкәндер...
Сөюебез — сүздә түгел, күздә —
Мәхәббәтнең балын эчкәнбез.

Болытларның йөзәр юлын ярып,
Ракеталар сузды ак тасма.
Минем үземне дә, каенны да
Син ошаттың шунда атласка.

Кызыл җиләк тулы ал учымны
Иренеңә илтәм — сыйланчы!
Мәхәббәтне, җәйне, тынычлыкны
Икәү эчик әле туйганчы!..

Йолдызлар тулы күк йөзе —
серле дә, тылсымлы да.
Кояшлы, айлы, йолдызлы
серле күк булсын гына!

Гашыйклар йолдыз санасын,
ай янсын ялгыз гына.
Мәңгелек моңын сөйләсен
кичләрен ялгызыма.

Сыгылсын сыным сагыштан,
түгелсен кайнар яшем.
Түзәрлек: илдә тынычлык,
башкалар кебек яшим!

Үз хәсрәтем — бер үземә,
илгә хәсрәт иңмәсен.
Илнең тыныч күген көн дә
реактивлар иңләсен —
илгә афәт килмәсен!..

Мин Уралда түгел — Урал алды
Кама буйларында туганмын.
Су эчкәнмен Сөрмәт чишмәсеннән,
Ык суында битем юганмын.

Язмыш мине Урал якларына
Китерде дә шунда калдырды:
Урал цехларында чыныктырды,
Мартен утларында яндырды.

Яланаяк бастым ташларына,
Биек тауларына үрләдем.
Юллар үттем, ташлы шул Уралдан
Матур якны ләкин күрмәдем.

Яшь кулларым белән корыч койдым,
Ә язылган җырлар азмы соң?!
Урал — минем җырлы тормышым ул,
Урал — минем кырыс язмышым!..

— Исәнме, Марзия кызым! Зур шатлыгыбыз бар бит әле — оныгым кияүгә чыга.

— Ә Сез, Фәгыйлә апа, матурланырга җыендыгыз алайса?!

— Әйе, Марзия кызым, туйга өр-яңа күлмәк киеп барырга ниятләдем әле. Менә тегеп тә бирсәгез инде... Яраткан тегүчеләрем кулыннан үткән киемне кисәм, яшәреп киткәндәй булам. Утыз елга якын шушында, сезнең янга йөрим бит...

— Кичә кызыгыз да пальтосын алып китте. Үз кызының туена яңа пальтодан бара инде алайса.

— Әйе. Шатлыгы эченә сыймаган. Кичә кенозын Розага рәхмәт укыды. Бигрәк килешле теккән шул.

Ателье мөдире Марзия Кадыйрованың Фәгыйлә әби белән шулай җылы сөйләшүенә кабул итүче кызлар да игътибар иттеләр. Хәер, алар моңа күнегеп беткәннәр иде инде. Уналты ел буе шушы 38 нче ательега җитәкчелек итә бит Марзия апалары. Әйе, 1947 елдан бирле шушы сферада эшләгән, Көнкүреш хезмәте күрсәтү отличнигы булган бу ханым кемгә кайсы төс, нинди фасон килешкәнлеген бер карауда белә шул. Ателье бусагасын атлап кергән һәркемне ачык йөз белән каршы ала. Әнә, Фәгыйлә әбиләр кебек туган-тумачалары белән шушында кием-салым тектерергә йөрүчеләрне дә өйрәнеп беткән ул.

Фәгыйлә әби күлмәклеген өстәлгә җәеп салгач, Марзия Вазыйховнаның йөзе җитдиләнеп китте. Моны сизеп алган әби сумкасын актарырга кереште һәм тагын бер төргәк тартып чыгарды.

— Ике төрле ситсы алып килгән идем, ошаганын сайларсың инде...

— Менә монысы, Фәгыйлә апа, зәңгәр кыр чәчәкләре сибелгәне бик тә килешле булачак. Күзләрегез төсенә дә туры килә икән,— дип ул кабул итүче кызларга да сораулы караш ташлады.

Ателье да хуҗасына ошаган, диярсең, килеп керүгә үк үзеңне иркен сизә башлыйсың. Бернинди дә киеренкелек юк, күңелләр рәхәтләнеп китә. Кешеләрдә ышаныч, ихтирам арта... Үзенең бизәлеше, милли сурәтләр ясалган колонналары һәм алардагы көзгеләр, гөлләр — һәммәсе күңелне үзенә җәлеп итә.

Вестибюльдә хезмәт алдынгылары, остазларның фоторәсемнәре эленгән. Кабул итү өстәле янында тәкъдимнәр кенәгәсе. Баксаң, аны «рәхмәтләр кенәгәсе» дип атарга бик мөмкин икән. Кемнәрнең генә телдән әйтелеп бетмәстәкәнмәс сөенеч-шатлыклары һәм рәхмәтләре шушы ак кәгазь юлларына салынмаган?!

«...Пөхтәлеккә, бары тик яхшы мөнәсәбәткә генә корылган ателье бу. Монда кәеф бозылмый. К. М. Рафикова, А. С. Ботова кебек мөлаем хезмәткәрләр клиентлар белән искиткеч яхшы мөгамәләдә. Заказларны үтәүче барлык мастерларга да «рәхмәт!» кенә әйтәсе килә. Бу коллективны җитәкләүче Марзия иптәш Кадыйровага һәм барлык ателье хезмәткәрләренә иҗади эшләрендә илһам, яңадан-яңа уңышлар телим...»— дип яза заказчы Зарипова. Бу кенәгәнең кайсы гына битен ачып карасаң да, «...югары культуралы хезмәт күрсәткәннәре өчен...» дигән җөмләләргә тап буласың.



Мастерлар Рәмзия Санзапова белән Нажия Нуруллова яңа тегелгән пальтоны карыйлар.

...Киеме дә матур булырга тиеш



Ателье белән танышканда, открыткаларга да күзем төште.

— Без открыткалар ярдәмендә заказлар кабул итәбез. Заказчыга уңай. Хәзерге заманда хатын-кызлар материаль һәм рухи байлык җитештерү өлкәсендә эшлиләр бит. Производстводан аерылмыйча укыйлар. Бала тәрбиялиләр. Заказчының кадерле вакытын җәлләү максатыннан чыгып кертелгән чара бу,— ди Марзия Вазыйховна. Открыткалар арасында мастерлар Р. Габдрахманова, Н. Нуруллова, Р. Санзапова тегүен үтенгәннәре дә байтак.

— Шушы ветеран кызларыбыз белән таныштырам,— дип, Марзия апа мине кышкы киемнәр тегү цехына алып керде.

Клиентлар язганча, көләч йөзле ханымнар алар. Уртача яшьтәге мастерларны бирердә олылап, «Хезмәт ветераны» дип йөртәләр икән.

— 1959 елдан бирле биредә эшлим. Кешеләрне матур итеп киендерергә тырышабыз,— ди Нажия Нуруллова елмаеп. Аның белән бер үк вакытта диярлек Рәмзия Санзапова да ательега эшкә килгән. Икесе дә училище бетереп, хезмәт юлларын шушында башлаганнар. һәм менә чирек гасырлык хезмәт биографияләре бергә үрелеп бара. Бу дуслар әле күптән түгел генә «Татшвейбыт»ның Мактау грамотасы белән бүләкләнгәннәр.

Кызлар кышкы кием тегәләр. Мисалга пальтоны гына алып карыйк. Аның төсе, фасоны, тегелеше — кешенең холыкфигылен дә чагылдыра. Ә кемнең генә күркәм характерлы, ыспай, мөлаем булып күренәсе килми соң? Хатын-кыз бигрәк тә таләпчән. Аны канәгатьләндерү өчен кисүчеләр, тегүче-осталар никадәр күңел җылысын салалар ул өс киемнәренә!

— Мин эшкә килгән елларда, халык ике генә төсне: ак белән караны гына белә иде, ә хәзер... Өс киеменең төсе аның йөзенә, чәч төсенә тәңгәл килә аламы, гәүдәгә ятышлымы-юкмы — барысын да исәпкә алып кына тектерәләр. Пальто кебек киемнәрне ел саен тектереп тә булмый. Шулай да һәр пальто заман таләпләреннән, модадан артта калмаска тиеш,— ди Рәмзия Санзапова.

Әйе, кешене киеменә карап каршы алалар, акылына карап озаталар, ди бит халык. Ателье хезмәткәрләре моны исләреннән чыгармыйлар.

— Заказчыны үлчәмгә кабат-кабат йөртеп, аның кадерле вакытын югалту әйбәт күренеш түгел. Без моны булдырмаска тырышабыз. Җиде кат үлчәп, бер кат кисү безнең девизыбыз,— ди Нажия апа әңгәмәгә кушылып.

— Мондый «нечкә күңеллелек» планга сукмыймы соң?— дим мин уенынчынын бергә кушып.

— Һич юк, ай саен планны 103—105 процентка үтәп барабыз. Узган елгы йөкләмәбезне үтәдек. Яңа елны да уңышлы гына башлап җибәрдек,— ди мөдир Марзия Кадыйрова.

Бу коллектив белән танышканда, ателье «туган» 1956 елны ук биредә эшли башлаган, үз эшен яратып, янып-көеп башкарган остаз Роза Габдрахманова турында да бик күп матур сүзләр ишеттем мин биредә.

Кулы-кулга йокмый, җитез хәрәкәтләр белән ул әле пальтога җәй ясап куя, әле уйланып тора да, тагын эшкә керешә... Карап-карап тордым да: «Чыннан да аларның эше иҗади бит»,— дип уйладым. һәм шушы фикеремне Роза апага да әйттем.

— Әйе, сеңлем, һәр пальтоны теккәндә яңача уйлыйсың. Безнең кулга драп та, мех та, табигый һәм ясалма күн дә, замш та килеп керә. Бу материалларны бозмыйча, кешеләрнең югары зәвыгына туры китереп тегәргә тырышабыз.

Боларның берсе дә бушка китмәгән. Хәзер әнә Роза Абдулловнаның күкрәгендә «Аеруча хезмәт күрсәткән өчен» медале балкый.

Алар бер муенсадагы сәйләннәр шикелле, берсен дә берсеннән аерып алып булмый. Әмма һәр асылташ үзенчә ялтырый, нур сибә. Нәкъ шулар шикелле, бу ателье хезмәткәрләренең дә үз биеклеге, үре бар. Алар шул үрләрне яулыйлар.

Зәрия АСЫЛОВА.

Р. ЯКУПОВ фотосы.

Ләбибә ИХСАНОВА

ХИСЛӘР УРТАКЛЫГЫ

Ана баланы йокларга яткырды, өстенә япты, утны сүндерде дә йокы бүлмәсеннән чыгып китте.

— Йокла, улым, сиңа йокларга вакыт,— диде ул.

Шулай итеп, баласында мөстәкыйльлек сыйфаты тәрбиялим, дип уйлый иде ана. Ләкин, бер акыллы кеше әйткәнчә, ул нәкъ дүрт елга соңга калган иде. Дүрт яшьлек баланың алай тиз генә тәрбияләнәсе килмәде, аның инде үзенең теләге, үз уе, үз дәгъвасы бар иде. Бу юлы да шулай булды.

— Мине әтием йоклатсын,— дип көйсезләнә торгач, ата кеше, телевизор каршыннан кузгалып, улы янына утырырга мәҗбүр булды.

— Нигә йокламыйсың инде? Әниеңнең сүзен тыңларга кирәк бит.

— Ә син миңа әкият сөйләрсеңме?

— Я, тыңла алай булгач. Борын-борын заманда булган, ди, Айрат исемле бер малай.

— Ул мин бит, әйеме, әтием?

— Әйе, ул син инде. Шул Айрат дигән малай бик батыр булган...

— Әтием, әтием,— ди малай, сүзен әйтеп бетерә алмаудан түземсезләнеп, ата кешенең күкрәгендә нәни кулларын биетеп ала,— ә син батырмы?

— Һм! Куркак түгел идем болай.

— Ә син фашистлар белән сугыштыңмы?

— Ул чакта мин юк идем әле.

— Ә ник юк идең?

— Әти белән әни алып кайтмаган.

— Ә ник алып кайтмаган, акчалары булмаганмы?

— Акча түгел, вакытлары булмаган. Әти сугышта йөргән.

— Аның мылтыгы булганмы?

— Мылтыксыз сугышып булмый бит, улым. Я, йокла.

— Әтием, ә син миңа сугыш турында сөйлә.

— Мин сугышны күрмәдем шул. Аны син дә күрмәсәң иде, балам. Телисеңме, мин сиңа солдатлар турында сөйлим. Синең әтиең солдат булган кеше бит.

Малайның күзләре ялтырап китә, ул урыныннан торып утыра, юрганын аяк астына ук тартып китерә дә, ир кешенең ил алдындагы изге бурычы турында булган чын хикәяне тыңларга җыена.

Кешенең бик кечкенәдән омтылган яхшы сыйфатларының берсе батырлык булгандыр, мөгаен. Ә батырлыкның үзен без илне саклау бурычы белән янәшә куеп карарга өйрәндек. Шул турыдагы әкиятләр, дөнья күргән кешеләрнең хикәяләре бала вакыттан ук күңелебездә гражданлык сыйфатлары тәрбияләргә ярдәм итте.

Бала чакта без үзебез тумышлары белән үк тәрбияче булган шундый олы кешеләр янына сырыша торган идек. Ул чакта әле тормыш та хәзергегә караганда авыррак, сабанны сука белән сөрәләр, игенне урак белән уралар иде. Өйләрдә кер юу машиналары, тиз генә аш-су җиткереп ала торган газ плиталаре дә юк иде. Шулай да кешеләр берберсе белән күбрәк аралаштылар. Өлкән яшьтәге кешеләр авылның тымызык җәйге кичләрен әле булса сагынып сөйлиләр. Көтү артыннан күтәрелгән тузан басылган, һавада җылы сөт исе, төн гөлләренең исе. Кичке эшләрен бетергән, тәмле чәен эчкән кешеләр капка төбе саен ял итеп утыра. Бер җирдә ир-атлар, тәмәке пыскыта-пыскыта, дөнья хәлләрен сөйләшәләр, икенче урында хатын-кызлар, алар тирәсендә җылы җиргә аяк бөкләп утырган бала-чагалар. Балалы өйдә гайбәт булмый, дигән сүз бар. Балалар булган җирдә сүзе дә икенчерәк була бит аның. Биредә күбрәк уен-көлке, олыларның кул чабып торулары, нәниләрнең тыпырдап биюләре, көйле-көйсез тавышлары белән тырышыптырышып җырлаулары була.

Кышкы озын кичләрдә тыңлаган әкиятләрне онытырлык кынамы соң? Әгәр күңелебездә әзме-күпме яхшылык, батырлыкка әзер тору, бәлагә төшкәнне йолып алырга омтылу, көчсезләргә булышу кебек сыйфатлар бар икән, аларның күпмеседер шул борынгы әкиятләрдән күчкән ләбаса. Һәр авылның үзенең данлыклы әкиятчеләре булган. Оста итеп сөйли белгән кебек, матур итеп ялындырганнар да алар. Кирелектән, ялкаулыктан түгел, бары тик сүзенең кыйммәтен, әкиятнең тәмен арттыру өчен шулай эшләгәннәр. Бу әкиятләрне тыңлар өчен ниләр генә эшләргә әзер түгел идек без!

Безнең очның бала-чагалары күбрәк Зәйнә абзыйларга керергә яратабыз. Аларның җиһаз белән кысрыкланмаган иркен өе теләгән бер баланы сыйдыра. Иптәш кызыбыз Фәрхинурның әтисе ул Зәйнәгыйтдин абзый. Колхозыбызның беренче председателе Фәрхетдин абзый да аның улы. Үзе дә башлап колхозга кергән, күмәк хуҗалык өчен җир бүлгәндә, беренче буразнаны сызган кеше. Шул вакытны кулаклар аны, башка колхозчылар белән бергә, ташлар ата-ата басу түреннән куарга маташканнар. Тәбәнәгрәк буйлы, киң җилкәле, чал кергән куе сакал-мыеклы күршебезне авылда Карл Маркс дип йөртәләр иде. Бала чагымда мин, аның кыяфәте стенадагы юлбашчының рәсеменә ошап торганга шулай әйтәләр, дип уйлый идем. Алай гына булмаган икән, соңыннан аңладым. Шулай янып-көеп яңа тормыш төзүдә катнашып йөргәнгә күрә пролетар юлбашчының исеме белән атаганнар икән аны. Зәйнә абзый гражданнар сугышы елларында да күпне күргән кеше. Безнең авыл тирәсендә ул елларда бик каты сугышлар булган. Башта авылны Колчак гаскәрләре алган, озак та үтмәгән, акларны куып, азинчылар килеп кергән. Ярмәкәй тау итәгендәге үлән баскан окоп чокырларын үзебезнең дә барып караганыбыз булды безнең. Шул тирәдә чәчелеп калган гильзаларны җыеп кайтабыз, шартламый калган гранаталарның яшькелт-сары күкертен чыгарып, олыларның котын алабыз. Менә шул сугышларда авылдан качкан аклар атлары белән ир-атларны да алып китәргә тырышканнар. Бу бәлагә Зәйнә абзый да эләгә язган, ләкин, алданрак сизенеп, караңгы төндә авылдан чыгып киткән. Аның Вятка буе урманнарында адашып йөрүләре, ачтан интегүләре, яңадан аклар кулына эләгә язулары, көннәрдән бер көнне атын урлатуы, дошманнар кулыннан качып киткән авылдашларын очратуы, мең бәла белән кызылларга килеп кушылулары — күңелебезне әсир иткән иң кызык әкиятләрдән дә кызыграк иде бу хәлләр. Күз күрмәгән, колак ишетмәгән еракләрдагы патша кызлары, пәри егетләре башыннан үткән маҗаралар гынамы соң инде болар! Үзебез җиләк җыеп йөргән урманнарда, үзебез су коенган, балык каптырган елга буйларында булган хәлләр. Шушы баш әйләндергеч вакыйгалар эчендә кайнаган кеше үзе каршыбызда. Әнә ул гөлдерәп янган тимер мич җылысынарак утырган да бертуктаусыз чабата ясый. Үзе чабата ясый, үзе безгә күргән-белгәннәрен сөйли.

Мәскәүдә авыл хуҗалыгы күргәзмәсе ачылгач, алдынгы колхозчылар булганга, иң элек Зәйнә абзый белән сыер савучы Әминә апаны күргәзмә карап кайтырга җибәрделәр. Мин үзем ул бәхеткә сугыштан соң гына ирешә алдым. Үсмер чакта Зәйнә абзый сөйләгәннәрдән алган тәэсирләрем онытылмаган иде әле. Кайсы гына павильонга килеп керсәм дә, аның мәзәк итеп я чын күңелдән шаккатып сөйләгәннәре исемә төшә дә елмаеп куям.

Бер аның хикәяләре генәме соң? Фронтлардан кайткан авылдашлар, башларыннан үткән героик һәм фаҗигале хәлләрне сөйләп, ул вакыттагы яшүсмерләргә күпме батырлык сабагы бирделәр.

Хәзер кешеләрнең күбрәк йөрергә, күбрәкне күрергә мөмкинлекләре бар. Аларны хәзер нужа тартып йөртми, күбрәк акча эшләүдән бигрәк романтика, яңа җирләр күрергә теләү, ташып торган көчләрен нинди дә булса илкүләм эшләргә салу омтылышы туган нигезләреннән алып китә. Чит җирләрдә йөреп кайткан кешенең мәртәбәсе элек-электән зур булган. Бик мактанасы килгәч, әйткән ди бит шулай бер бабай: «Син — карчык, кем белән яшәгәнеңне белеп тор, Ташлы Ярдан әйләнеп кайткан кеше булыр синең картың»,— дигән, ди. Ә Ташлы Яр дигәне унбиш чакрымдагы волость авылы икән. Казан белән район арасын да самолетта гына утырып оча торган бүгенге заман кешеләре көлеп сөйләгән сүз инде бу. Ә алар үзләре кайларга гына барып йөрмиләр. Илебезнең әле бер, әле икенче ягында күтәрелгән зур төзелешләр авыллардан да, шәһәрләрдән дә яшь, таза, гайрәтле кешеләрне чакырып кына тора. Кайсы гына гаиләгә барып керсәң дә, Себер тайгаларында агач кискән, чирәм җирләр күтәрүдә катнашкан, КамАЗ салышкан, БАМда эшлә-

гән, балык флотилиясендә йөзгән, метро корган, югары көчәнешле электр баганалары утырткан, тагын әллә кайларда әллә нинди эшләр башкарган кешеләрнең берәрсен очратмый калмыйсың. Ләкин, ни хикмәттер, эшләрен менә дигән итеп эшли белгән шушы кешеләр җанны рәхәтләндерерлек итеп күргән-белгәннәрен сөйләргә ашыкмыйлар. Ә бит алар дөньяны әлегә китаплардан укып кына белгән, тәҗрибәгә түгел, хыялга бай булган үсмерләргә ни кадәр кызыклы сүзләр сөйли алган булырлар иде. Йөргән юлларының романтикасын гына димик, авыр һәм драматик якларын күрсәткәндә дә, тыңлаучылар гыйбрәт алыр, ә инде дөнья күргән кешеләр үзләре башкарган эшләр белән дә таныштырсалар, бик күп яңа һөнәрләрдән мәгълүмат бирерләр иде. Җыелышларда, лекция залларында ишеткән сүзләрнең файдасы күп, билгеле, әмма күзгә-күз сөйләшеп утыруның тәме башкачарак, җан җылысын тоеп торганда, ышану көче дә артыграк була. Якын кешең бит ул синең, көн дә күрешеп, аралашып, бер чишмәнең суын эчеп, бер үк юлларны таптап йөргән кешең. Күңелең сусаганны, ишетергә теләгәнеңне сөйләтә аласың син аннан, туйганчы бәхәсләшергә дә булдырасың, кирәк булса, сораулар биреп йөдәтергә дә тартынмыйсың. Ул сөйләгәннәрне нәкъ үзең күргәндәй кичереп утырасың, ул алган җәрәхәттән синең дә тәнең сызлана, аның шатлыгы синең дә йөрәгеңә кагыла.


Билгеле, хәзер андый әңгәмәләргә мохтаҗлык юк, элек кенә ул, китап һәм радио тансык булган, телевизорның ни икәнен дә белмәгән заманнарда кирәк булган ул капка төбе утырышлары, дип әйтергә дә мөмкин. Чыннан да, китап хәзер теләсә кемнең үз өендә. Түр башында телевизор утыра, аклы-каралы гына түгел, күбесендә төсле телевизор, бор да җибәр шуны — җаның теләгән нәрсәне карый аласың. Кино дисәң, шәһәрдә генә түгел, авылда да хәзер көн саен кино күреп була. Әйе, анысы шулай. Информация чыганаклары хәзер кирәгеннән артык күп. Ләкин шуларны дөрес файдаланырга өйрәтүче акыллы киңәшче генә янибызда һәрвакыт булмый.

Ә телевизорны карыйсың да торып китәсең, китапларны да укып бетерүгә ябып куясың. Алган тәэсирләрең белән уртаклашырга теләсәң дә ялгыз син. Нинди дә булса тапшыру караганнан соң, я берәр әйбәт китап укып чыккач, яхшы кино карап кайткач, өйдә җыелып утырып сөйләшкәнебез, шулар турында фикер алышканыбыз, бәхәсләшкәнебез бармы соң безнең? Бу әйбәт гадәт бардыр ул барын, рухи байлык белән яши торган кешеләр аңар вакыт кызганмый торганнардыр, аларның ихтыяҗына әйләнгәндер бу хәл. Ләкин, һәр гаиләдә шулай, дип әйтеп булмый әле. Бу бик кызганыч, әлбәттә. Тәрбиянең менә дигән үтемле чарасын гына түгел, үзара җылылыкны көчәйтү җаен да кулдан ычкындырабыз икән бит шулай. Андый кичәләр гадәткә кереп китсә, гаилә әгъзалары бер-берен аңлау сәләтенә өйрәнерләр, якынлыклары тагын да артыр, бала-чагалар да ул сәгатьләрне көтеп алырлар, урамда шар сугып йөрү урынына, кызыклы әңгәмәләрдә катнашып, күбрәк вакытларын өйдә, олылар янында үткәрерләр иде. Андый кичәләр, ниһаять, балаларны үз фикерен әйтә алу, кирәк икән, аны яклый белү осталыгына да өйрәтер, шул чагында бәхәсле урыннар ачыкланыр, бала күңелендә җавапсыз калган сораулар булмас, әле генә караган тамаша, я укылган китап та вакыт үткәрү чарасы булып түгел, җан азыгы булып рухны баетыр, хәтердә озаграк сакланыр иде.

Бала яратмаган, аны сөендерергә теләмәгән кеше юктыр ул. Аларның күңелен табу өчен ниләр генә эшләмибез. Кечкенә чакларында өсте-өстенә уенчыклар алабыз, үсә төшкәч, берсеннән-берсе матуррак киемнәр юнәтергә тырышабыз. Шул теләкләребезгә ирешкәч, балаларыбыздан бигрәк үзебез шатланабыз. Ләкин бала уенчык белән бераз уйный да туя, ватып ташлый, матур киемгә дә тиз ияләнә, кадерсезли, кызыгын тапмый. Ә бит дусларча кызыклы әңгәмәләрнең әле беркайчан да, бер кешене дә туйдырганы юк. Сөйләсәң сүз чыга, ди безнең халык. Һәр сүзнең, вакытына һәм җаена карап, үз тәме, үз кыйммәте һәм файдасы була. Моның өчен кайдадыр барып, эзләнеп, борчылып йөрүнең кирәге дә юк. Моның өчен фәкать вакытны гына кызганмаска кирәк.

Күп вакыт та сорамый үзе, кичке чәйгә җыелып, өстәл янында утырганда, бергәләп савыт-саба җыйганда яки, бөтен мәшәкатьне бетереп, берәр кул эше тотканда сөйләшеп була торган сүзләр. Биш минут, ун минут, күпкә китсә ярты сәгатьлек дусларча әңгәмә никадәр рәхәтлек бирер иде. Үкенечкә каршы, без өйдә берәр борчу булганда гына олыдан кубып сөйләшәбез, соңга калып сөйләшәбез.

Бөтен гаилә бергә җыелгач. **Ф. ГОБӘЕВ фотосы.**



ТУГАН ТЕЛ ОСТАСЫ

Төмәннән чыккан автобус сәгать ярым эчендә табигатьнең аулак почмагына, куе урман ышыклыгына сыенган Акъяр авылына китереп тә җиткерә. Авылның уртасыннан узган Акъяр елгасы ярьягында иксез-чиксез болын җәелеп ята. Кырыс, артык купшы булмаган Себер табигатенең үз яме бар. Тын урман да, киң болын да, сабыр гына аккан елга да көннән-көн матурлана барган бу авылның борынгы тарихын сер итеп саклыйлардыр шикелле тоела. Чал тарихка әйләнгән узган еллар, ата-бабалар белән булган бәйләнешне үземе саклап торган истәлекләрнең берсе — халыкның ана теле. Себер диалектының әдәби татар теленнән шактый аермасы булган үзенчәлекләре бөек Тукай телен яратып өйрәнергә һич комачауламыйлар. Мәктәптә укый башлагач, балаларның беренче ятлаган шигырьләре дә сөекле шагыйрьнең сүзләре:

«И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле,

Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы».

Акъяр сигезьеллык мәктәбе — Төмән өлкәсендә татар телен һәм әдәбиятын укыту мәсьәләләре буенча терәк мәктәп. Бу мәктәптә фәнни-практик конференцияләр, семинарлар һәм кызыклы очрашулар үткәрелә.

Бу үрнәк дәресләрне иҗат итүче укытучы — РСФСР мәгариф отличнигы, коммунист Люция Бадретдиновна Хәбибуллина. Ул Акъяр мәктәбендә утыз беренче елын эшли инде. Барлык фәннәр рус телендә укытыла торган бу мәктәптә, җирле диалект та көчен югалтмаган шартларда, укучыларның чын әдәби телдә сөйләгәннәрен тыңлап, укытучының ничек тырышып эшләгәнен тоясың.

Акъяр мәктәбендә ана теленә карата булган зур ихтирамны мәктәп ишеген атлап керүгә күрәсең. Каршыда Герой-шагыйрь Муса Җәлилгә багышланган зур стенд. Аның янәшәсендә торган ишек татар теле һәм әдәбияты кабинетына алып керә. Сине Люция Бәдретдиновна каршы ала. Кара күзләреннән ташып чыккан җылы нурлар аның кара-туткыл чибәр йөзен тагын да сөйкемлерәк итеп күрсәтәләр.

Класс каршында Әхмәт Ерикәйнең портреты эленгән. Кучермә киштәдә аның шигырьләренең җыентыклары куелган. Матур итеп эшләнгән плакатта Әхмәт Ерикәйнең түбәндәге сүзләре язылган:

«Гашыйк булган сыман юлда егет

Җилдән җитез чапкан атына,

Мин гашыйкмын сиңа, туган илем,

Син чын байлык минем зәвкыма».

Димәк, 5 класста шагыйрьнең иҗатына багышланган әдәбият дәресе булачак.

Күргәнебезчә, укучыларда югары әхлак сыйфатларын, эстетик зәвык, дөньяга коммунистик караш һәм югары патриотик хисләр тәрбияләүдә Люция Бадретдиновна, методик алымнар белән бергә, төрле сәнгать чараларыннан гаять оста файдалана.

Татар язучыларының, композиторларының, художникларының портретлары белән бизәлгән кабинетта стендлар яңартылып, әледән-әле алышынып торалар. Аларда күренекле татар язучыларының әсәрләре, «Казан утлары», «Азат хатын», «Ялкын» журналлары тупланган. Алар язучыларның тормыш һәм иҗат юлларын тирәнрәк ачарга ярдәм итә, әдәбиятның башка сәнгать төрләре, рус һәм башка милләтләр әдәбияты белән тыгыз бәйләнешен күрсәтә торган гаять бай материаллар бирә.

Муса Җәлил турында тирән эзләнүләр нәтиҗәсендә мәктәпнең пионерлар дружинасы Герой-шагыйрь исемен йөртү хокукына лаеклы булган.

1965 ел мәктәп тарихына әдәбият бәйрәме елы булып кереп калган. Ул елны бер төркем язучылар: Зәки Нури, Әхмәт Исхак, Атилла Расих, Илдар Юзеев, Туфан Миңнуллин, Мәрзия Фәйзуллиналар Төмәндә татар әдәбиятының атналыгын үткәрәләр. Акъяр укучылары, укытучылары һәм авыл халкы алдында ясаган чыгышлары зур истәлекле вакыйгага була. Акъяр мәктәбендә атна буе алар иҗатына багышланган кичәләр үткәрелә. Мәктәп тарихы альбомында бу язучылар, Хәсән Сарьян, музыка белгече Мөхмүт Нигъмәтҗанов, Советлар Союзы Герое Михаил Девятаевлар истәлек язулары калдырганнар. 1984 елда Акъяр мәктәбендә үткәрелгән фәнни-практик конференциягә килгән галимнәр — тел һәм әдәбият дәреслекләре авторлары Бәйрәм Мифтахов һәм Гөлчәчәк Әдһәмова белән очрашулар да балаларга көчле тәэсир ясады.

Акъяр халкы җырдан һәм шигырьдән аерылмый яши. Авыл сәхнәсендә яңгыраган нәфис сүз, җыр, гармонь моңын тыңлар өчен клубка бөтен Акъяр халкы җыела. Үзешчән сәнгатьтә даими катнашкан кешеләр дә аз түгел. Шулар арасында Ниязова Сөембикәнең балалары аерылып торалар. Тамашачылар нәфис сүз осталары Рәхмәтулла һәм Мәүлет Ниязовларны, Гали һәм Вәли Мирасовлар башкаруындагы лирик җырларны бигрәк тә җылы каршы алалар. Нәфис сүз һәм җыр сөюче, үзе дә үзешчән сәнгатьнең актив катнашчысы Люция апаларының киңәшләрен игътибар белән тыңлыйлар.

Ана теленә булган мәхәббәт халкыбызның матур традицияләрен сакларга да ярдәм итә. Акъяр кешеләре тыйнак, пөхтә, ачык йөзле һәм кунакчыл. Яшь кызларда һәм киленнәрдә бик матур бер гадәт сакланган: Акъярга суга төшкәндә, алар өс-башларын алыштырып, матуррак киенеп чыгарга тырышалар. Каз өмәләре, туйлар авыл бәйрәмнәренә әверелә. Күп балалы гаиләләр дә еш очрый бу авылда. Акъяр кешеләренең балаларын сөеп-яратып үстерүләре дә ата-бабалардан буыннан-буынга күчеп килгән халык педагогикасының нигезләрен кадерләп саклауларын күрсәтә.

Люция Бадретдиновна Төмән өлкәсенең Вагай районында, борынгы татар авылында туып, сабый чакларын шул авылда үткәрә. Бу — Шәйхи Маннур «Агымсуларга карап» исемле романында җылы итеп искә алган Тукыз исемле авыл. Әтисе Бәдретдин Гарифуллович Татарстанның Кама Тамагы районы, Кариле авылыннан 20 нче елларда, Тобол округына грамотасызлыкны бетерү эшенә килә. Округтан ул милиционер итеп Тукызга җибәрелә. Авылның бер чибәр кызына өйләнеп, гаилә кора. Тукызга китапханәче булып килгән Шәйхи Маннур белән Бәдретдин Гарифуллин арасында шушы авылда туган дуслык әдипнең соңгы көннәренә кадәр өзелми. Акъярда яшәүче пенсионер Бәдретдин ага, Тобол округында партия эшендә чагында, өлкәдә беренче татар мәктәпләрен ачып, аларның эшен җайга салып җибәрә. Соңыннан 40 ел буе татар мәктәпләрендә директор булып эшли. Бәдретдин аганың ун баласының бишесе укытучы һөнәрен сайлап ала. Аларны тормыш юлына озатканда, Бәдретдин ага болай ди: «Укытучы эше — изге эш. Авырлыклардан курыкмагыз. Балалар тәрбияләү — бәхет ул». Әтисенең эшен улы Изил дәвам итә. Төмән өлкә мәгариф бүлеге инспекторы буларак та, партиянең өлкә комитеты инструкторы буларак та татар мәктәпләренең эшендә сизелерлек эзләр калдыра. Тарих фәннәре кандидаты Изил Бәдретдинович Гарифуллин әле дә җаваплы эштә.

Люция Бәдретдиновнаның Себер табигатенә һәм халкына булган җылы хисләре, мөгаен, Яркәү районының Кәешкүл авылында тугандыр. Анда Бәдретдин ага, җидееллык мәктәп ачып, шактый еллар директор булып эшли. Люция, Кәешкүл мәктәбен тәмамлап, Тобол татар педагогия училищесына укырга керә һәм Кәешкүлгә укытырга кайта.

Сугыштан соң Люция, укуын дәвам итәр өчен, Казанга килеп, педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты факультетына керә. Белемгә сусап килгән Себер кызы лекцияләрне йотлыгып тыңлый, үзлегеннән күп укый. Классик татар әдәбиятына мәхәббәт уяткан доцент Җамал Вәзиева, совет әдәбияты белгече Мәдинә Җәләлиева кебек остазларына күңелендә рәхмәт хисе саклый ул. Казанда укыган елларын иң бәхетле, кадерле еллары итеп искә ала. «Без, студентлар,

шигъри дөньяда яшәдек, атна саен әдәби җомганы көтеп ала идек. Анда язучылар үзләренең яңа әсәрләрен укыйлар. Ул кичәләрдә язучылар белән очрашу чын бәхет була иде»,— ди ул.

Ана телен һәм әдәбиятын укытуның изге бер бурычы — интернационализм, халыклар арасындагы дуслык һәм бердәмлек хисләрен тәрбияләү. Бу бурычны үтәүдә Люция Бәдретдиновнага, шигъри җанлы, эмоциональ табигатьле булуы өстенә, киң эрудициясе дә ярдәм итә.

Люция Бәдретдиновна белән рус теле укытучылары балаларга ике телне дә камил үзләштерергә ярдәм итү чараларын бергәләп эзлиләр, үзләре иҗади бер группа тәшкил итәләр. Дәресләргә хәзерләнгәндә фикер алышалар, әдәби кичәләрне бергәләп үткәрәләр. Татарстан кызы Розаның, Казан дәүләт педагогия институтында белем алып, Акъярга килеп рус телен укыта башлавына да 30 елдан артык вакыт үтте. Ул, Себерне үз итеп, матур гаилә корып, Акъярда яшәп калды. Аның намуслы иҗади хезмәте «РСФСР мәгариф отличнигы» дигән исем белән бәяләнде.

Акъяр мәктәбенең башка укытучылары да иҗади хезмәтләреннән ямь табып яшиләр. Бу талантлы укытучылар коллективы белән РСФСР мәгариф отличнигы Хатип Хотбуллович Хәбибуллин җитәкчелек итә. Ул да Казан дәүләт педагогия институтында белем һәм тәрбия алган кеше. Әлмәт егете Хатип, институтны тәмамлагач, сөйгән кызы Люция белән аның туган ягына себергә килә. Матур эшләгән кебек үк, матур яшиләр Хәбибуллиннар, ике кыз һәм бер ул үстерәләр. Аларның инде һәркайсының үз гаиләләре, балалары һәм яраткан һөнәрләре бар.

Акъяр мәктәбендә башлап белем алган яшьләр белән укытучы арасында элемтә өзелми. Илебезнең нинди генә почмакларында яшәмиләр алар: эшчеләр, нефтьчеләр, инженерлар, врачлар, укытучылар, совет офицерлары. Совет Армиясе командирларыннан яшьләрне чын гражданнар, ил сакчылары итеп тәрбияләүләре өчен мәктәпкә һәм ата-аналарга рәхмәт хатлары килә.

Баланың «һәрвакытта аңлаешлы шатлыгы, кайгысы» булган ана теле, моңлы Тукай, тормыш һәм матурлык җырчысы Һади Такташ, илнең батыр улы Муса Җәлил, нечкә лириклар Әмирхан Еники һәм Сибгат Хәким, олы җанлы Гомәр Бәширов һәм Хәсән Туфаннар Акъяр кешеләренең мәңгелек юлдашлары булып калалар. Алар матурлык, гаделлек һәм туган ил сакчысы булырга өндәп торалар, катлаулы тормыш юлларында абынырга ирек бирмиләр.

Менә тагын яз бәйрәме — 8 нче Март җитте. Бу көнне кадерле укытучыларына: «Барысы өчен дә рәхмәт Сезгә, апа!» — дип әйтер өчен, чәчләре агара башлаган кешеләр, март җилләре суыгыннан саклап, Акъярга тере чәчәкләр алып кайталар.

Бибинур САБИРОВА,
Түбән укытучылар белемен камилләштерү институтының милли мәктәпләрдә рус һәм ана теле укыту кабинеты мөдире.



Безнең Мөкәрәмә

Күптән түгел Дәүләт банкысының Татарстан конторасы коллективы безнең хезмәттәш иптәшебез Мөкәрәмә Нургалиевна Вәлиеваның финанс органнарында өзлексез эшләвенә 50 ел тулуны зурлап билгеләп үтте. Ярты гасыр! Әйтергә генә ансат. Һәрвакыт җыйнак һәм пөхтә, зәвык белән матур итеп киенә белә торган, мөлаем йөзле Мөкәрәмәгә карап, аның үз яшен бирерлек тә һәм, бер урында, шундый җаваплы постта 50 ел буе эшләгәндер, дип уйларлык та түгел. Чит кешеләр моңа, бәлки, ышанмаслар да инде.

Мин үзем аның белән 30 ел бергә эшләдем. Дәүләт банкысы конторасына ул 17 яшьлек кыз чагында килә. Бөтен күңелен куеп, эшкә бирелә. Алны-ялны белми, укый, өлкәннәрдән өйрәнә, тәҗрибә туплый. Шулай итеп, еллар уза. Тора-бара Мөкәрәмә үзе дә остазга әйләнә. Ниһаять, гади бер бухгалтердан акча әйләнеше һәм хезмәт хакы фондына контроль группасы начальнигы дәрәҗәсенә кадәр күтәрелә. Бу — банк эшендә бик җаваплы участок. Акчаның туктаусыз әйләнешен тәэмин итәргә, хезмәт ияләренә эш хакын үз вакытында түләүне булдырырга, завод һәм фабрика, предприятие һәм учреждение, саклык кассалары ихтыяҗларын тулы канәгатьләндерергә, хуҗалык органнарының эш хакы фондын дөрес тотуларына даими контроль ясарга кирәк. Моның өчен финанс эшен энәсеннән-җебенә кадәр җентекләп белү, үзеңә һәм кул астында эшләүчеләргә нык таләпчән булу, акча әйләнешенең катлаулы мәсьәләләрен кыю һәм принципиаль рәвештә хәл итә алу, гомумән һәрьяклап киң эрудицияле булу таләп ителә. Һәм Мөкәрәмә Нургалиевна үзенә йөкләтелгән вазифаларны искиткеч төгәллек белән үти. Шуның өчен дә аның абруе гаять зур, ул — тирән ихтирам казанган кеше.

Мөкәрәмәнең хезмәт кенәгәсендә ике генә язу бар. Бөек Ватан сугышы алдыннан гына Коммунистлар партиясе сафына кергән хезмәттәшебезне Дәүләт банкысының Яңа Кенәр бүлекчәсенә управляющий итеп җибәрәләр. Ул шунда биш ел эшләп, сугыш беткәч кенә әйләнеп кайта.

Безнең өчен Мөкәрәмә актив җәмәгать эшлеклесе буларак та бик якын. Ул — 30 ел буе безнең местком председателе, партбюро члены. Күп тапкырлар профсоюз өлкә комитеты члены булып сайланды, ике тапкыр дәүләт учреждениеләре работниклары профсоюзы съездына делегат булып Мәскәүгә барды.

Местком председателе һәм партбюро члены буларак, Мөкәрәмә бигрәк тә коллективтагы яшьләрдә үз һөнәрләренә мәхәббәт, аңлы дисциплина, хезмәткә коммунистик караш тәрбияләүгә зур көч куя. Шул ук вакытта ул кешеләр ихтыяҗына ифрат та игътибарлы. Аңа күп төрле үтенечләр белән мөрәҗәгать итәләр. Кемнеңдер баласын ясле-бакчага урнаштыруда ярдәм итәргә кирәк, кемдер авырып киткән — больницага саласы була, кайсыныдыр ял йортына — санаторийга җибәрәсе бар. Эштән күптән киткән пенсионерлар турында да кайгырта ул, хәлләрен белеп тора, мөмкин кадәр ярдәм итәргә тырыша.

— Ничек син барысына да өлгерәсең, вакыт табасың, гаиләң, балаларың, оныкларың да бар бит? — дип сорыйбыз без аңардан.

— Әлбәттә, җәмәгать эше күп вакытны ала. Әмма кешеләргә игелекле булу, кечкенә генә булса да яхшылык эшли алу — үзе күңелне күтәрә, дәртләндерә бит,— дип җавап бирә ул.

Әйе, безнең Мөкәрәмә үзенең бөтен эшчәнлеген шәхси тормышы белән акыллы рәвештә бергә бәйләп алып бара белә.

Аның хезмәт һәм тормыш юлы, җәмәгать эшчәнлеге Дәүләт банкысы работникларының күп буыннары өчен үрнәк булып тора, дип әйтер идем мин. Аның күкрәген «Хезмәттәге батырлык өчен», «1941—1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында батыр хезмәт өчен», «Хезмәт ветераны» медальләре бизи. Ул күп тапкырлар КПСС өлкә комитеты һәм ТАССР Министрлар Советы, СССР дәүләт банкысы идарәсе, дәүләт учреждениеләре работниклары профсоюз Үзәк Комитетының Почет грамоталары белән бүләкләнде.

Без, Мөкәрәмәнең хезмәттәш иптәшләре һәм дуслары, аны чын күңелдән ихтирам итәбез, аңа киләчәк тормышында да зур уңышлар, бәхетле һәм шатлыклы көннәр телибез.

Мәрьям ХАЛИТОВА.



Бәйрәм каршылаганда

Бәйрәм каршылаганда без барыбыз да кием шкафларындагы күлмәкләребезне барлап чыгабыз, яңасын да булдырабыз. Туганнарыбызга, дус ишләребезгә күркәм күренәсебез килә. Хатын-кызлар, ничә яшьтә булуына карамастан, пөхтә, нәфис һәм матур булырга омтыла һәм шулай булырга тиеш тә. Бу җәһәттән бит-йөз кыяфәте дә мөһим. Биттәге җыерчыкларны киметүгә тукландыргыч кремнар һәм төрле маскалар ярдәм итә. Алар бит тиресен купшаклanудан саклый, аны тукландыруны, кан әйләнешен яхшырта.

Кремнарны, үзеңнең бит тиресе үзенчәлеген истә тотып, даими кулланырга киңәш ителә. Коры тирегә йомшарткыч компонентлары күп булган майлы кремнар сөртелә. Аны биткә бармаклар белән җиңелчә хәрәкәтләр ясап сөртәләр дә 30-40 минут тоталар, артыгын кәгазь салфетка белән сеңдереп алалар. Кремны көннең теләсә кайсы вакытында да, йокы алдыннан да сөртергә мөмкин.

Тиресе майлы булган кешеләргә биткә тоныклык төсмере өсти торган майлы булмаган кремнар сөртергә тәкъдим ителә. Витаминлы, тукландыргыч, сафландыргыч маскалар теләсә нинди тирегә файдалы. Алар атнага бер мәртәбә тукландыргыч крем белән бергә ясала. Масканың иң гадие — үсемлек майларыннан ясалганы. Ул тирене тәрбияләүнең иң файдалы чарасы. Күз, авыз, чигә тирәләрендәге җыерчыклар күренүгә, майлы маска ясый башларга кирәк. Бераз җылытылган үсемлек маен биткә сөртеп, 15-20 минут тоталар. Биттәге калган майны мамык белән сак кына сөртеп алалар да, җылы компресс ясыйлар. Аннан соң салкынча компресс ясалса, бигрәк тә әйбәт.

Мондый масканы майонездан да ясыйлар. Бит тиресе төссез һәм сәлперәя башлаганда, ромашка, юкә чәчәге, каен яфрагы, бөтнек, сары мәтрүшкә төнәтмәләреннән эсселе-суыклы компресс ясау файдалы. Компресс ясаганнан соң, битнең нинди булуына карап, крем сөртәләр. Бите майлы булган кешеләргә чүпрә маскасы аеруча файдалы. Моның өчен 10-15 г чүпрәне сөткә салып изрәтәләр (ул каймак куелыгында булырга тиеш) дә биткә сөртәләр.

Сула башлаган коры тиреле биткә гөлчәчәк таҗларыннан, аю баланы (бузина) чәчәгеннән, ромашкадан ясалган төнәтмәләр уңай тәэсир итәләр.

Хатын-кызлар өчен җәй— җиләк-җимеш, яшелчә чоры аеруча күңелле вакыт. Мәсәлән, кыяр маскасының агарту үзлегенә ия булуы күп хатын-кызларга мәгълүм. Түтәлдән өзеп кенә алынган кыярның кабыгын биткә буй-буй тезәләр дә, марля белән каплап, ятып торалар. Җир җиләгенең помидор яисә угычтан үткәрелгән торма белән катнашмасы да битне агартып җибәрә. Әмма аны биттә 15 минуттан артык тотарга ярамый.

Сез бик арыгансыз, ди. Әмма сезгә кеше арасында булырга кирәк, я кунакка, я театрга барырга кирәк. Мондый очракта сезгә сафландыргыч маска ярдәм итәр. Моның өчен 1 йомырка сарысы, бер кашык бал, берничә тамчы лимон суы һәм сөт алына. Барысын бергә болгаталар һәм куелату өчен солы көрпәсе салалар да биткә ягалар. Аннан соң битне юып, ромашка төнәтмәсеннән компресс ясыйлар.



Чүлмәк ашлары

Соуслы йомырка. 4 кеше өчен: 8 йомырка, 100 г гөмбә, 2 баш суган, 1 рюмка коньяк, 100 г каймак, 60-70 г атланмай, тоз, борыч кирәк.

Соус болай әзерләнә: гөмбәне чистартып юыгыз, турагыз да майның яртысында кыздырыгыз. Телемләп турап, суган, коньяк, каймак, тоз, борыч өстәгез, болгаткалап кыздыруны бераз дәвам итегез дә плитәдән алыгыз.

Калган май белән дүрт чүлмәкне майлагыз һәм һәрберсенә 2 шәр йомырка сытыгыз, тоз сибеп мичкә тыгыгыз. Йомырка агы куеру белән, кире алыгыз да әзер соус сибегез һәм табынга бирегез.

Гөмбәле суфле. 4 кеше өчен: 60-70 г атланмай, 1 баш суган, 150 г гөмбә, 4 аш кашыгы он, 300 г сөт, 1 стакан уылган сыр, 2 йомырка, тоз, борыч кирәк.

Суганны турап, майның яртысында кыздырыгыз, юылган, ваклап туралган гөмбә өстәп, 2-3 минут томалап пешерегез, тоз, борыч сибегез һәм 4 чүлмәккә бүлеп салыгыз.

Калган майда онны кыздырыгыз, сөт өстәгез, болгаткалап, 1 минут кайнатыгыз. Аннары тоз сибеп болгатыгыз да сыр йомшарганчы пешерегез. Плитәдән алыгыз да йомырка сарысы кушыгыз, аннары, күбеккә әйләнгәнче туглап, йомырка агы өстәгез һәм соусны тигезләп гөмбә өстенә бүлеп салыгыз. Суфлены кайнар мичтә 20-25 минут пешерегез дә мичтән алгач ук табынга бирегез.

Запеканка. 1 кеше өчен: 2 аш кашыгы вак кына итеп туралган суган, 100-120 г җебетелгән брынза, кабыгы әрчелгән (консервланган) бер помидор, 2 аш кашыгы атланмай, 1 йомырка, әз генә туралган өче борыч (теләгән кешегә), тоз, борыч кирәк.

Йомыркадан башка барысын да чүлмәккә салыгыз да уртача кызулыктагы мичтә 15 минут пешерегез. Аннары, өстенә йомырка сытып, тагын 5 минут пешерегез. Кыздырылган ипи белән ашагыз.

Көнчыгыштагыча. 1 кеше өчен: 100 г тапалган ит (сыер һәм бозау итен кушсаң әйбәт), 2 аш кашыгы вак кына туралган башлы суган, 2 аш кашыгы сөт, тоз, борыч, 1 йомырка, 1 аш кашыгы атланмай кирәк.

Йомыркадан башкаларын бергә кушыгыз да котлет кебек итеп ясагыз. Майланган чүлмәккә салыгыз да кызу мичтә, өсте кызарганчы, 15-20 минут пешерегез. Мичтән алып, бер йомырка сытыгыз. Эретелгән май сибегез дә тагын 6-7 минут пешерегез. Кайнар килеш ашагыз.

Венгрларча. 1 кеше өчен: 1 аш кашыгы вак кына туралган башлы суган, 50-60 г брынза (тозлырак сыр да яхшы), 50-60 г ветчина (яисә колбаса), 50-60 г сыр, 0,5 күпертелгән йомырка, 1 кузак ачы борыч, бераз кызыл төелгән борыч, 2 аш кашыгы атланмай кирәк.

Чүлмәк төбенә суган, аннары ветчина, аннары сыр телеме, өстенә май кисәкләре салыгыз, борыч сибегез (теләгән кеше 1 кузак ачы борыч сала ала) дә уртача кызу мичтә 15-20 минут пешерегез, аннары өстенә күпертелгән йомырка коеп, тагын 3-4 минут мичтә тотыгыз.

Яшелчә белән ит. 4 кеше өчен: 3/4 кг бозау яки сыер ите, 1 банка стерилизацияләнгән яшелчәләр катнашмасы, 1 баш суган, 0,5 кг бәрәңге, 4 аш кашыгы атланмай, 1 аш кашыгы вак туралган петрушка, тоз, төелгән кызыл борыч кирәк.

Итне 8 кисәккә бүлегез дә майда кыздырыгыз, туралган суган, тоз, борыч, бераз кайнар су өстәп, әзер булганчы томалап пешерегез. Бәрәңгене әрчеп, шакмаклап турагыз да, ит, яшелчәләр белән кушып болгатып, һәрберсендә 2 кисәк ит булырлык итеп, тигезләп чүлмәкләргә бүлеп чыгыгыз, өстенә петрушка сибеп, кайнар су өстәп, уртача кызулыктагы мичтә пешерегез.








Бу модельләрне
Казандагы
Модалар йорты
тәкъдим итә.





МОДАЛАР




Л. КУЗНЕЦОВА фотолары.





Соңгы елларда рәссам бик нәфис һәм шактый көйсез материал — ефәк белән эш итә. Ул ефәк ашъяулыкларга, яулыкларга, күлмәкләргә ачык бизәкләр ясый, ә кайбер очракларда «Идел», «Сабан туе» кебек тулы картиналар иҗат итә. Ефәктә бу ысул белән рәсемнәр ясау батик дип атала. Иҗат эшенең бу юнәлешендә дә София Даниловна халык сәнгатенә таянып эшли.


Ул халкыбызның рухи мирасын саклауга, аны бүгенге көнкүрешкә кертүгә һәм киләчәккә җиткерүгә хезмәт итә. Ә халык иҗаты аңа рәссам буларак киң колач белән иҗат мәйданына чыгарга мөмкинлек бирә.

Гүзәл **СӨЛӘЙМАНОВА**,
сәнгать белеме кандидаты.



Биредә сез София Даниловна Кузьминых иҗат иткән кайбер әйберләрне — мендәр тышларын, сумкаларны, акча янчыгын һәм батик ысулы белән бизәлгән яулык — күрәсез.
Р. Мансуров фотолары.







Р. Якупов фотосы.

ФЕСТИВАЛЬНЕ КАРШЫЛАП



Узган елның декабрь аенда, Казанда беренче мәртәбә джаз һәм эстрада оркестрларының смотры булып узды. Яшьләр Үзәгенең концертлар залында күп кенә һәвәскәр коллективлар үзләренең осталыгын күрсәттеләр һәм тамашачыларның мәхәббәтен казандылар. Арада иң яхшылары белгечләр тарафыннан югары бәяләнде.

Бу смотрда чыгыш ясаган группаларның берсе — ТАССРның X еллыгы исемендәге культура сараеның «Фантазия» исемле джаз-группасы — кызлардан гына тора. Бу рәсемдә сез шул кызларны күрәсез. Группаның җитәкчесе — Татарстанның атказанган культура работнигы Ирек Фәтхетдинов.

Бәясе 25 тиен.
Индекс 73002.